# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2/ 2023

*Татарстанның Азнакай районында шәһәр тибындагы Актүбә бистәсе бар. Искиткеч матур балчык уенчыкларны шунда ясыйлар. Уенчыкларның темасы – татар халкының борынгы көнкүреше, көндәлек тормышы һәм бәйрәмнәре, фольклор типажлары. Уенчыклар гаҗәеп оптимистик рухта эшләнгән – чын сәнгать шундый булырга тиеш тә.*







# «Татарстанның мәдәни башкаласы» проекты

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



**Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан оештырылган «Татарстанның мәдәни башкаласы» проекты дәвам итә. Бәйгенең нәтиҗәләре ел ахырында – декабрь урталарында билгеле булачак. Җиңүче дип табылган муниципаль район «Татарстанның мәдәни башкаласы» исеменә һәм 3 миллион сумлык сертификатка ия булачак.**



## ЭЧТӘЛЕК


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **«Һөнәрчеләребез – мәдәни мирасның бер өлеше»**

6 **Татарстанда республиканың чиккән картасын ясыйлар**

10 **Татарстанда республиканың мәдәни башкаласын ачыклыйлар**

12 **Сабантуй дәресләре**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**



14 **Минем матур бизнесым**

**ӘДӘБИ МИРАС**



20 Л. Мөхәммәтҗанова
Д. Абдуллина
**Традицияләр сагында – татар дастаннары**

26 Р. Мәһдиева
**Эпос-дастаннарда тарихның чагылышы**



Түгәрәк уен
№2 (48) / 2023


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов



Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 13.06.2023
Чыгу көне: 26.06.2023
Заказ: 067087 Тираж: 1000 экз.



Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru



«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78




Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** «Чишмә буенда», «Кунаклар каршылау», «Айсылу» статуэткалары.
*Рәссам И. Сәлахова.*


© «Түгәрәк уен», 2023

**МИФОЛОГИК МИРАС**




30 Г. Гыйльманов
**Тыюлар – борынгы яшәү кануннары**


**СӘХНӘ**




36 А. Бәшәров
**Илфат Әскәров – «Кибәче Әлмәндәре»**


**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ**




40 М. Шәйхетдинова
**«Зәрә» бәйрәме**
*(Сценарий)*

45 Л. Хәкимова
**«Бүләк җыю» йоласы**


**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**


46 Г. Шәрифуллина
**Сатыш авылының данлыклы мәдрәсәсе**


**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**





48 **Йола фольклоры. Чәчүгә чыгу белән бәйле йолалар**


**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**




52 А. Әскәрова
**Чынга ашкан балачак хыялы**

57 **Җиңү көнендә**
(Җыр)


**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**




58 **Борай бәлеше**


**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**


62 **Шахворд**



# «Һөнәрчеләребез – мәдәни мирасның бер өлеше»

**2023 елның 22 мартында Казан Кремлендә халык һөнәрчелеге буенча сәнгать советы утырышы узды.**

Утырышта Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова, Мәдәният һәм сәнгать советы әгъзалары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, республиканың профильле ведомстволары һәм алдынгы мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре катнашты.

Рөстәм Миңнеханов осталарның эшләреннән торган күргәзмә белән танышты. Ул халык һөнәрчелегенең республика өчен генә түгел, тулаем илебез мәдәни мирасының мөһим өлеше булуын ассызыклады.

Кунаклар «Тархан» тарихи-мәдәни киносын ничек төшерүне күрделәр, Н.И. Фешин исемендәге сәнгать училищесы һәм Халык сәнгать һөнәрләре техникумы тарафыннан әзерләнгән мастер-классларны карадылар.

Утырышта халык сәнгате һөнәрчеләре һәм предприятиеләр тәкъдим иткән эшләнмәләрне югары сәнгать казанышы дип тану, аларны Татарстан Республикасы халык сәнгате һөнәрләре реестрына кертү, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында теркәлү мөмкинлекләре каралды. Экспертиза өчен 15 предприятие, шәхси эшмәкәр һәм үзмәшгульнең эше тәкъдим ителгән иде.

Утырыш кысаларында республикада мәдәниятне үстерүнең, Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын һәм Россиядә педагог һәм остаз елын гамәлгә ашыруның өстенлекле юнәлешләре, шулай ук тармак үсешенең заманча тенденцияләре турында фикер алыштылар.



**Алсу Мифтахова,**
**Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры:**

**“ Халык һөнәрчелеге – халкыбызның милли мәдәниятенең алыштыргысыз өлеше. Ел саен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы халык һөнәрчелеге тармагында эш итүчеләргә ярдәм йөзеннән грант конкурсы игълан итә. Быел осталарның әзерлеге һәм алар тәкъдим иткән эшләнмәләрнең сыйфаты артуын күрәбез. ”**





# Татарстанда республиканың чиккән картасын ясыйлар

**Татарстанда, Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан, «Татарстан Республикасының чиккән картасы» проекты башланып китте.**



Светлана Бартязова, Кайбыч районы



Кайбыч районы

Проектның максатлары – республиканың күпмилләтле халкының бердәмлеген арттыру, төбәгебездә халыкларның милли чигү осталыгын саклап калу, декоратив-гамәли сәнгать тармагында эшләүче осталарның иҗади үсешен тәэмин итү һәм һөнәри бердәмлеген арттыру.

Әлеге акциянең учредительләре – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Советы» ассоциациясе. Проектны Татарстанның мәдәни ресурс үзәге оештыра. Проектның партнерлары – Тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга булышлык итүче «Татнефть-Наследие» үзәге, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты,



**Биектау районы**



**Гөлшат Миңнебаева, Сарман районы**



**Сарман районы**

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Казанның халык һөнәрчелеге техникумы, Татарстанның Милли музее, «БЮРО БАНУ» остаханәсе.

Проект кысаларында Татарстанның 45 муниципаль районы чигү осталары үз төбәкләренең картасын чикте. Аннары әлеге өлешләр бергә тегелеп, Татарстан Республикасының тулы картасы булдырылды. 2 метрга 3 метрны тәшкил иткән бу карта июнь башында Чувашстан Республикасында узган «Чиккән



Алабуга районы





Балык Бистәсе районы

Россия» Бөтенроссия фестивалендә катнашты. Ел дәвамында, әлеге фестивальдә катнашучы төбәкләрнең чиккән карталары белән, илнең барлык төбәкләре дә танышып чыгачак.

«Татарстан Республикасының чиккән картасы» проекты 2023 елның февралендә башланып китте. Алдан рәссамнар район картасының эскизын ясады. Һәр район картага үзләренең җирлегендә булган иң танылган, борынгы яисә данлыклы объектны кертергә тырышты, төбәк ия булган үзенчәлекне тасвирлады, районда яшәгән халыкларның милли үзенчәлеген күрсәтергә тырышты. Аларга проектның консультантлары ярдәмгә килеп, эскиздагы объектларны дөрес итеп урнаштырырга, картаны чиккәндә дөрес җепләр кулланырга, төсләрне сайларга булышты. Аннары эшкә чигү осталары кереште. Алар рәссамнар ясаган эскизлар буенча кулдан районнарының картасын чикте. Ахырда барлык кисәкләр бергә тоташтырылып, Татарстанның йөзен тасвирлаган уртак карта ясалды.





Арча районы



Актаныш районы



Ләйлә Галимова, Актаныш районы

Проект кысаларында республиканың 3 метрга 5 метрны тәшкил иткән картасы да ясалды. Ул да кечерәк карта принципларында эшләнде. Зур карта Татарстанда калачак һәм республикада уза торган төрле чараларда, бәйрәмнәрдә, шулай ук Россия төбәкләрендәге күргәзмә-ярминкәләрдә катнашып, республикабызны, аның мәдәниятен, милли йөзен тәкъдим итәчәк.



Арча районы

# Татарстанда республиканың мәдәни башкаласын ачыклыйлар

**Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан оештырылган чараларның иң саллысы һәм масштаблысы буларак «Татарстанның мәдәни башкаласы» проектын атап була.**

Бәйгене Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Советы» оештыра. Проект Татарстан районнарының тарихи-мәдәни мирасын саклау, мәдәни үсешне тәэмин итү, төбәкләрнең туристик һәм инвестицион мөмкинлекләрен арттыру, милләтләр дуслыгын ныгыту, муниципаль берәмлекләрнең уңай имиджын, үз брендларын булдыру, бердәм мәдәни киңлек формалаштыру максатында уздырыла.

Агымдагы елның 31 мартыннан башлап 24 ноябренә



Кама Тамагы районы



Сарман районы

кадәр Казанның төрле мәдәният мәйданчыкларында Татарстанның һәр муниципаль районы мәдәни программа тәкъдим итә. Аның кысаларында халык һөнәрчелеге үрнәкләре, төбәкнең үзенчәлеген тәшкил иткән йолалар, аш-су үрнәкләре, гореф-гадәтләр күрсәтелә, төрле осталык дәресләре, мастер-класслар уза. Халык үзешчәннәре һәм районның профессиональ мәдәният осталары тарафыннан оештырылган бай программалы зур концертлар үтә.

Проект кысаларында һәр район төбәкнең культурологик паспортын да булдырды. Анда җирлекнең төп социаль һәм мәдәни күрсәткечләре, туристик маршрутлары, җирле үзенчәлекләре тасвирланган.

Республиканың кайбер муниципаль районнары инде үзләренең программаларын тәкъдим дә итте. Алар арасында Лениногорск, Нурлат, Сарман, Яңа Чишмә, Кама Тамагы, Әлки, Арча, Чирмешән, Менделеевск, Апас һәм башка районнар бар.

Бәйгенең нәтиҗәләре ел ахырында – декабрь урталарында билгеле булачак. Җиңүче дип табылган муниципаль район Татарстанның мәдәни башкаласы исеменә һәм 3 миллион сумлык сертификатка ия булачак. Бу акчага җиңү яулаган районда федераль яисә региональ мәдәни проект тормышка ашырылачак.


Сарман районы

# Сабантуй дәресләре

**Быелның 26-28 апрелендә Казанның Габдулла Тукай әдәби музеенда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге Сабантуй бәйрәмен оештыручылар һәм режиссёрлар өчен семинар-практикум уздырды.**

Россия Федерациясе регионнары – Тверь, Волгоград, Мәскәү, Киров, Курган, Омск, Томск, Ульян, Пенза, Нижегородск, Оренбург, Төмән, Самара, Чиләбе, Новосибирск, Кемерово, Ростов, Свердловск, Әстерхан, Владимир, Иваново, Калининград өлкәләреннән; Бурятия, Коми, Удмуртия республикаларыннан; ХМАО-Югра округыннан; Ставрополь, Краснодар, Пермь, Приморски, Забайкалье крайларыннан һәм чит илләрдән килгән 50 кеше алдында югары уку йортлары галимнәре, танылган мәдәният һәм сәнгать әһелләре, Көрәш федерациясе вәкилләре чыгыш ясады. Бәйрәм режиссурасы, мәйданчыкларны, бәйрәм осталарын әзерләү, бизәү тәртибе һәм башкалар буенча лекцияләр үтте.

Семинарның теоретик өлешен үзләштергән кунаклар Татарстанның Теләче районында булып, биредә аларга Сабантуй бәйрәменең прологын күрсәттеләр. Шунда ук татар аш-суын әзерләү буенча осталык дәресләре дә үтте.

Катнашучыларга сертификатлар тапшырылды.




**Дамир Натфуллин,**
**Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары:**

> **“Сабантуй тормыш образына әйләнгән бәйрәм. Вакытлар үткән саен аның ниндидер яңа төсмерләре барлыкка килүе табигый, ләкин база калырга тиеш. Прогресс казанышларына игътибар итү белән бергә бәрәттән тарихыбызны һәм милли үзенчәлекләребезне дә онытмаска иде.”**







Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# МИНЕМ МАТУР БИЗНЕСЫМ

**Соңгы елларда милли татар чигеше модага керә башлады. Кием дә, аксессуарлар да, интерьер предметлары да чигеп бизәлә. Халыкның гасырлар дәвамында формалашкан чигү традицияләренә профессиональ осталар да зур өлеш кертә – Наталья Евгеньевна Гыймадиева шуларның берсе.**

Мин Казанда тудым һәм хәзер дә Казанда яшим. Кул эшләрен яратуым әбиемнән һәм әниемнән күчкән. Әбием тегә, эрли, бәйли иде. Әнием фигуралы шуудагы һәм биюдәге чыгышларым өчен костюмнарны үзе тегеп киендерде. Әмма үзем бу һөнәргә тиз генә килмәдем. Югары юридик белеп алгач, ТНВ телерадиокомпаниясендә эшли башладым. Бервакыт тапшыруга Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы директоры Раушания Сәүбанова килде. Танышып-сөйләшеп киттек тә, Раушания Кыяметдиновна мине техникумга чакырды. Мин аңа бик рәхмәтле – татар мәдәнияте буенча техникум миңа тирән белем бирде.

Техникумнан «Костюмнар рәссамы» белгечлеге алып чыктым, татар чигешенең гүзәллеген дә техникумда тойдым. Чигәргә өйрәнү өчен сәнгати һәм эстетик зәвык кына җитми, теләк һәм түземлек тә кирәк. Милли орнаментларны да, бизәкләр төзелешен дә, чигү төрләрен дә һәм, әлбәттә, халык сәнгатенең кыйммәтле ядкәре булган милли кием үзенчәлекләрен дә белергә кирәк.

Безгә чигү һәм бизәкләр буенча беренче дәресләрне Елена Юрьевна Угрюмова бирде. «Кызлар, сез булдырасыз», – дип илһамландырып торучы да ул иде. Техникумны кызыл диплом белән тәмамладым.

Укыганда ук еш уйландым: милли чигешнең матурлыгын нигә музейларда, сәхнә костюмнарында һәм сувенир продукциясендә генә күрәбез



“

***Милли орнаментларны да, бизәкләр төзелешен дә, чигү төрләрен дә һәм, әлбәттә, халык сәнгатенең кыйммәтле ядкәре булган милли кием үзенчәлекләрен дә белергә кирәк.***

”













соң әле без? Ул көндәлек киемдә дә була алмыймыни? Нәзакәтле татар чигешеннән уникаль бренд ясау идеясенә шулай килдем.

Башта үзем өчен тектем, үзем өчен чиктем, аннары якыннарыма бүләк өчен эшли башладым. Матур гына килеп чыга иде. Ә бер елдан – 2019 елда – үзмәшгуль булып теркәлеп, авторлык татар чигешле киемнәр тегүче «Гүзәллек» брендын барлыкка китердем.

2020 елдан Татарстан Республикасында халык һөнәрчелеге үсешенә багышланган күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, фестивальләрдә һәм башка проектларда актив катнаша башладым.

Ә инде клиентлар базасы арткач, Казанның үзәгендә – Иске татар бистәсендә «Гүзәллек» брендының остаханәсен ачу мөмкинлеге туды.





***Милли чигешнең матурлыгын нигә музейларда, сәхнә костюмнарында һәм сувенир продукциясендә генә күрәбез соң әле без? Ул көндәлек киемдә дә була алмыймыни?***







Уникаль урын татар һөнәрчелегенең кадерен белүчеләрне үзенә тарта башлады. Ошаганын сатып алырга яки күңелең теләгәнчә итеп заказ бирергә мөмкин. Сәхнә костюмнары да, корпоратив униформа да әзерлибез. Кием-салымнан тыш, авторлык чигеше булган букчалар, йомшак аяк киеме, күзлек савыты, мендәр, калфак, шамаилләр, күн брошьлар да ясыйбыз.

Остаханәдә чигү курслары ачып җибәрдек. Төрле техникада – канитель белән укалап, элмәләп (тамбур), шома чигү һәм башка төрләрне өйрәтәбез, осталык дәресләре уткәрәбез.


Грант акчасына шома чигү өчен машина алу да эшебезне җиңеләйтте, әмма бу әле кеше машина белән генә идарә итә дигән сүз түгел, һәр эшләнмәдә останың кулы бар: ул бизәкләрне әзерли, төсләр сайлый, әйбернең дизайнын күзаллый.

Сәнгать-эксперт шурасына эшләнмәләрнең киң ассортиментын тәкъдим иттем: мендәрләр, фермуарлы букчалар, күлмәкләр.

Шундый «матур бизнес» булдыра алуыма сөенеп туя алмыйм. Илһамланып татар чигешен заманча киемнәргә кертәм, татар бизәкләрен популярлаштырам – бу мәдәни кодны саклау да, татар тарихының һәм традицияләренең бер өлеше булган чигүче һөнәрен тергезү дә.



# Бергәләп бизибез!



# ТРАДИЦИЯЛӘР САГЫНДА – ТАТАР ДАСТАННАРЫ

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



*Диләрия АБДУЛЛИНА,*
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*



### ДАСТАННАР ЕЛЫ ТАТАР ДАСТАНЫН АЧАРМЫ?

Бөтендөнья татар конгрессы быелгы елны Дастаннар елы дип игълан итте. Бу бер дә очраклы хәл түгел, татар эпос-дастаннары мондый игътибарга чын-чынлап лаек. Татар дастаннарының үзенчәлеген, кыйммәтен аңлау өчен киң тарихи-мәдәни мәйдан кирәк. Дастаннар елы игълан ителү – бүгенге татар җәмгыятендә эпос-дастаннарыбыз феноменын ачуга таба зур бер адым.

Тарихи барышка игътибар итеп, үткәнгә әйләнеп карасак, күрәбез: халык күңелен тетрәндерерлек вакыйгалар һәрвакыт зур иҗат булып бәреп чыга, иртәме-соңмы алар күләмле җитди әсәр буларак таныла. Ә дәүләт тоткан татарның озын-озак тарихы мәшһүр вакыйгаларга бик бай.

Татарлар – дастанлы халык. Дөньяда эпос-дастаны булмаган бик күп халыклар бар. Эпоска мөнәсәбәттә шуларны да исәпкә алганда, дастаннарыбызның аеруча зур хәзинә булуы аңлашыла. Татарда дастан барлыкка килү тенденциясе һәм эпик иҗатка омтылышның тамырлары тирәндә. Тикшеренү өлкәсендә татар дастаннарына XX йөзнең 20-нче елларыннан әһәмият бирелә башлаган булган, шул елларда ук халыкка билгеле мәгълүм дастаннарның җыйнама вариантларын төзү бурычы да куелган. Әмма чорның иҗтимагый-сәяси шартлары милли эпосны өйрәнелүдән дә, үстерүдән дә озак вакытка мәхрүм иткән.


Дастаннарны көн кадагына кую, мәсьәләгә кабат әйләнеп кайту, алар хакында янә сүз кузгату фәкать XX йөзнең икенче яртысыннан соң



**Татар фольклор мәктәбенең эпос белгечләре Фатих Урманчеев, Лилия Мөхәммәтҗанова, Илсөяр Закирова. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011 ел**

гына мөмкин булды. Ф. Урманчеев, М. Госманов, Ф. Әхмәтова-Урманче, Д. Исхаков, Н. Хисамов, Ф. Яхин, В. Хәйруллина, М. Әхмәтҗанов, М. Гайнетдин, Л. Ибраһимова, М. Бакиров һәм башкаларның дастаннарны төрле аспектларда тикшергән монографик хезмәтләре, зур-зур мәкаләләре дөнья күрде. XXI гасырның унынчы елларыннан алып Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре И. Закирова, Л. Мөхәммәтҗанова-Ибраһимова, Ф. Вәлиуллина, А. Фәхретдинова, Г. Хөсәенова тарафыннан дастаннарга багышланган докторлык, кандидатлык диссертацияләре якланды, дастаннарыбыз хакында киң колачлы монографияләр, фәнни һәм популяр матбугатта саллы мәкаләләр дөнья күрде, дастаннар хакында радио-телевидениедә чыгышлар да активлашты.

Моннан тыш, мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Татар халык иҗаты»ның татар телендә 25 томлыгы, рус телендә 15 томлыгы әзерләнеп килә, берничә том, шул исәптән рус телендә «Дастаны» китабы инде дөнья күрергә дә өлгерде. Сүз уңаеннан, татар дастаннарының академик җыентык буларак рус теленә тәрҗемәдә әле моңа кадәр басылып чыкканы юк иде. Татар телендә чыга торган күптомлыкның «Дастаннар» һәм «Китаби дастаннар» дип аталган ике томы шулай ук әзер. Томнар татар дастаннарының иң камил үрнәкләрен үз эченә ала, томнарда дастаннарның халыкта билгеле вариантлары хакында тулы фәнни мәгълүмат




**«Каһарман Катил» дастанының Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә саклана торган кульъязмасы**

бирелә. Шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан ел саен уздырыла торган «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбенең чираттагысын татар дастаннарына багышлау, эпик мираска багышлап китап чыгару һәм башка чаралар планлаштырылган. Дастаннарга карата күрсәтелгән мондый игътибар фольклор эпик ядкарьләребезнең иҗтимагый тормышта урынын билгеләүдә катнаша.

## ДАСТАННАР ИҖАТ ИТҮ ТРАДИЦИЯСЕ ӘЛЕ ДӘ ИСӘН!

Эпосны халыкка җиткерүче башкаручы-импровизатор иҗаты – язмага кадәрге культураның бер чагылышы. Эпосны телдән әйтү күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, мөселман культурасын соңрак үзләштергән яисә ислам тәэсирен бөтенләй кичермәгән халыкларда стабиль сакланган. Халык шигыренә нигезләп, зур-зур вакыйгалар турында тоташтан сөйләп бирү фольклорда дастан (эпос) жанры булып ныгыган. Татарларның иң оештыручы үзәге саналган Идел буенда эпосның мондый төре, ягъни көннәр-төннәр буе думбра чиртеп әйтелә торган беренчел формасына караганда язма-китаби төренә өстенлек бирелгән. Әлбәттә, тугандаш төрки һәм төрки булмаган халыкларга хас җыраулык-чичәнлек сыйфатлары да чит-ят түгел татар дастанына. Кайбер дастаннарыбызның шигъри өлешләрен дутар, думбра, саз белән көйләп әйтү традициясе исән булу, хушаваз һәм дастан җырларының бүген дә халыкта очравы шуңа дәлил. Институт тарафыннан 2000 нче еллар азагыннан интенсив төстә уздырылып килә торган, бүгенге көндә Институт эшчәнлегенең зур бер юнәлешен тәшкил иткән комплекслы фәнни экспедицияләрдә галимнәр татар дастаны эзләренә еш тап булалар.

Шулай да безнең халыкның дастан жанрында күләмле сөйләмә эпоска караганда китабилыкка, язма иҗат белән шөгыльләнүгә омтылыш күбрәк сизелә. Күрәсең, дастаннарның кыргыз, казакъ, каракалпак һәм башка халыклардагы кебек импровизатор тарафыннан башкарыла торган сөйләмә формасына караганда утрак тормышлы, уку-язуга омтылышлы Идел буе татарларының рухи тормышында язмачылык өстенлек алып, китаби дастаннар ныграк популярлашкан. Алтын Урда таркалганнан соң аның җирлегендә оешкан Казан ханлыгы, Кырым, Нугай, Әстерхан ханлыклары белән рәттән Себер ханлыгы да – Алтын Урда дәвамчысы, ул да этник, матди һәм мәдәни яктан Җучи олысы традицияләренә нигезләнеп яшәгән төбәк. Себер ханлыгы Казан ханлыгы язмышына соңрак – 1585 елда




**Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә саклана торган татар дастаннарыннан кайбер үрнәкләр**

дучар була. Оештыручы сәяси үзәктән ераклык, шулай ук территория киңлеге һәм башка факторлар эпос-дастаннарның яшәве өчен дә уңайлырак шартлар барлыкка китергән. Себердә әле XX гасыр урталарынача күләмле эпосны телдән әйтүче осталар булган. «Мешәк алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш мәргән», «Кара Күкел», «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» һәм берничә дистә вариантта «Идегәй» – чагыштырмача тыныч төбәккә сыенып, себер татарлары иҗатында исән калган сөйләмә дастаннарыбыз.

Ә Идел буенда, ягъни элекке Казан ханлыгы территориясендә яшәгән татарларда шул ук яисә башка сюжетлы дастаннар язма-китаби юл белән үскәннәр. Мәсәлән, «Идегәй», «Чура батыр», «Гыйсә улы Амәт», «Дастане Чыңгызнамә», «Алпамша», «Җик мәргән», «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы», «Түләк китабы», «Сары Салтык», «Хурлуга белән Хәмра», «Мактым-сылу», «Кыйссаи Зәркум», «Хикәят Былбылнамә», «Хикәя Маһфируз вә солтан илә Разанхан», «Каһарман Катил», «Кыйссаи Сәкам», «Кыйссаи Сәед Баттал», «Хикәяте Күр углы солтан» кебек дастаннарыбызның күпләгән вариантлары бар. Күп гасырлык язма мираска ия татарларда иртә язмачылык, утрак тормыш, шәһәрләшү, укымышлылыкның югары дәрәҗәдә булуы, грамоталылыкны һәм белемне пропагандалый торган ислам тәэсире дастанның язма-китаби юнәлештә үсүенә йогынты ясаган.

Татарның бик борынгыдан килә торган кульъязма китабы да, XIX гасырның башыннан дөнья күрә башлаган тулы канлы милли басма китабы да – мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнү өчен үтә кыйммәтле чыганак. Татарларның кульъязма һәм басма китабы аеруча бай һәм зур тарихка ия. Китап тарихын, бигрәк тә меңәрләгән кульъязма китапларны, шулар арасында дистәләгән исемдәге, йөзәрләгән варианттагы дастаннарны өйрәнү иң элек кульъязма материалны



«Каһарман Катил» дастанына Н. Фәрхетдинова рәсеме

туплаудан башлана. Казанда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында, аннан тыш Милли китапханә, Казан федераль университеты, Дәүләт архивы һәм башка фәнни үзәкләрдә татар дастаннарын җыю-туплау һәм сакланышын тәэмин итү юнәлешендә хаклы рәвештә максатчан эш алып барыла. Татарларда эпос-дастан бар гына түгел, бик күп, аларның иң камил, иң тулы вариантлары язмада саклана. ТӘһСИның Язма мирас үзәгендә генә дә әллә никадәр кульязма дастан барлыгы мәгълүм һәм аларның саны фәнни экспедицияләрдә табылган яңа вариантлары исәбенә ел саен арта тора.

## ДАСТАННАР – МӘКТӘПЛӘРДӘ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДА

Дастаннарда халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Халкыбыз хәзинәсе, башка халык авыз иҗаты үрнәкләре белән беррәттән, эпос-дастаннар – яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирасның мәктәптә әдәбият укыту программаларында тиешле урын алуы да шуның белән аңлатыла. Кулланылышта булган мәктәп программасы һәм дәреслекләр нигезендә укучылар дастан жанрының тарихы, төрләре белән танышалар. Мәхәббәт, алыплар турындагы дастаннар турында сөйләшү халкыбызның күңел байлыгын, идеалларын, матурлыкка омтылышын күзалларга ярдәм итә. Халкыбызның гасырларны кичеп, тарихның авыр, ээзәрлекләүле еллары аша үтеп, кабат укучысына кайтарылган «Идегәй» дастанын укып анализлау укучыны тормыш фәлсәфәсенә, гади дә, катлаулы да хакыйкатькә якынайта. Бу тарихи дастан Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларын, аның сәбәпләрен ачыклый. Әмма укучы өчен иң әһәмиятлесе, бабаларның яше, тире, каны тамган, шатлыгы да, бәхете дә, бөтен язмышы да шуңа сеңгән туган җир сүзенең асылын аңларга өйрәтә дастан. Мәкер, хыянәт, ялганның олысы, кечесе юк икәнлеген төшендерә. Дуслык, мәхәббәт хисенең сафлыгын, биргән вәгъдәгә тугрылыкның олылыгын таныта. Явызлык үзе белән явызлыкны ияртә, яманлыкка каршы кылынган яманлык аны үстерә фаҗигагә китерә дип раслый. Дастан укучының тормышка карашларын киңәйтә, зуррак масштабта фикерләргә, вакытның мәңгелек агышында кеше, аның гамәлләренең мәгънәсен төшенергә өйрәтә. Ил, ватан, милләт төшенчәсенең кыйммәтен аңлаган кеше үз гомерендә аларга хыянәт итәргә батырчылык итмәячәк. Милли мирасыбызны өйрәнүдә төп оештыручы үзәк булган Татарстан Фәннәр академиясе, аерым алганда, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мәгариф өлкәсендә татар дастанының әһәмиятен һәм кыйммәтен аңлап эш итә, татар дастанының мәктәп программаларында лаеклы урын алуына тиешле әһәмият бирелү, татар дастаннары темасының татар теле һәм әдәбиятыннан ел саен уздырыла торган республика, халыкара олимпиада сораулары арасына кертелүе нәкъ менә шуның белән аңлатыла да.

Дастаннар – буыннан-буынга тапшырылып килә торган олы мирас, бу байлыкны файдалану һәм килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерү, асылыбызны саклауны нәтиҗәле итә. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирас бүгенге көндә иҗтимагый тормышыбызда да билгеле бер роль башкара. Дастаннарның һәм дастаннардан килә торган традицияләрнең онытылмавы шул хакта сөйли. Бүгенге көндә дастан батырларының исемнәре, дастан вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә һәм әдәбият мәйданында яшәвен дәвам итә, дастаннарның бүгенге көндә халык тормышындагы чагылышына караган китаплар дөнья күрә – димәк, бүгенге татар җәмгыятендә эпос-дастаннар традициясенең яшәвенә ихтыяҗ бар.



**«Таһир белән Зөһрә» дастанына иллюстрация. Н. Хаҗиәхмәтов рәсеме**

## ТАТАРНЫҢ НӘКЪ ҮЗЕ КЕБЕК – ЯШӘҮЧӘН УЛ ДАСТАН!

Татар дастаннары үткән юл бик озын һәм катлаулы. Гомумән, эпос-дастаннарыбыз, милләтнең үзе кебек үк, гаять яшәүчән жанр. Нинди генә шартларга юлыкканда да татар эпосының исән калуы, яңадан-яңа отышлы формаларга трансформацияләнеп, камилләшә баруы шул хакта сөйли. Россиядә һәм чит илләрдә татарларның чәчелеп яшәүче халык булуы дастаннар үсешенә үзенең уңай йогынтысын ясаган дияргә мөмкин. Сибелеп урнашкан татар халкының, мисал өчен, себер яисә әстерхан этник төркемендә сөйләмә характердагы дастаннар күбрәк сакланып калып, Идел буендагы татарларда исә язма-китаби эпос-дастаннар тотрыклы үсеш алган булу да шуңа дәлил.

Китаби кануннар өстенлек алган язма дастаннарыбызга да, чабып барган ат тоягы тавышын, кошның очып һавага күтәрелүен, исеп үткән дала җилен, ат пошкыруын, кылыч чыңын сөйләмә аша тыңлаучыга җиткерергә сәләтле башкаручы тасвирындагы сөйләмә дастаннарыбызга да фольклор кануннары барлык тулылыгы белән диярлек сыешкан, аларда эпик һәм индивидуаль иҗат башлангычлары бер-берсе белән ярашып яши.

Татар дастаны – тарихи фактларны, татарларның борын-борыннан килгән яшәү рәвешен түкми-чәчми сөйли торган чыганак ул. Әйе, татар – дастанлы халык, ә инде аның язма-китаби дастаннары дәрәҗәсенә җиткерелгән версия-вариантлары башка бер генә төрки халыкта да юк. Татар дастанының китаби камиллеккә ирешкән булуы – милләтнең аңы, укымышлылыгы, алдынгылыгы белән бәйле сыйфат, шуңа да китабилык эпос-дастан жанрының асыл кыйммәтләреннән санала. Бүгенге көндә татар җәмгатьчелегендә дастаннарыбызга игътибарның зурлыгы исә бу кыйммәтле ядкарьләрнең тарихи, иҗтимагый, әдәби-мәдәни, тәрбияви-педагогик һәм башка әһәмиятле сыйфатларга ия булуына бәйле.

# ЭПОС-ДАСТАННАРДА ТАРИХНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Рабига МӘҺДИЕВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге методисты*




**Эпос – халыкның тормышын, милли йөзен тасвирлый торган тарихи әсәр, халык мәнфәгате өчен көрәшүче героик шәхесләр, каһарманнар турында поэма. Эпос борынгы грек телендә (ἔπος) – «сүз» дигәнне аңлата. Ул социаль төркемнәр барлыкка килгәнгә кадәр, ягъни ырулар чорында туа.**

Дастан фарсы сүзе (داستان) «хикәят» дигәнне аңлата. Якын һәм Урта Көнчыгышта, көньяк-көнчыгыш Азиядә таралыш алган лиро-эпик характердагы әсәр. Бу тарихи жанрдагы күпчелек әсәрләр шигырь белән язылган, шул ук вакытта проза белән язылганнары да очрый. Дастаннарда чынбарлык күренешләре әкияти сюжетлар, легенда-риваятьләр белән катнаштырып бирелә. Төрки һәм фарсы әдәбиятында, фольклорында эпос һәм дастан терминнары синоним рәвешендә дә кулланыла[1].

Тарихи дастан реаль вакыйгалар җирлегендә барлыкка килә һәм тарихи шәхес образын тудыра. Бу дастан һәм аның төп каһарманы Чура батыр образы фольклорчы галимнәр, эпос белгечләре тарафыннан шактый җентекле өйрәнелгән. Аңа багышланган диссертацияләр, махсус монографияләр бар. Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова (Ибраһимова), мәсәлән, 2000 елда «Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады, 2015 елда якланган, татар китаби дастаннарына багышланган докторлык диссертациясендә дә әлеге темага киң тукталды.

Татар һәм башка төрки халыкларда киң таралган «Чура батыр» дастанының төп каһарманы серле һәм әлегә кадәр тулаем ачылмаган шәхесләрнең берсе. Әмма аның халкыбыз тарихында гаять зур роль уйнаганы бәхәссез. Румыниядән алып ерак Себер урманнарына кадәр таралган татар авылларында дастанның бик күп вариантлары йөрү – шуның ачык мисалы. 1988 елда

[1] Мөхәммәтҗанова Л.Х. Тарих булып дәшә Чура батыр... // Казан утлары. – 2015. – № 9. – Б. 180-183.



**«Идегәй» китабына иллюстрация (Казан: Тат. кит. нәшр., 1994). Рәссам Р. Шәмсетдинов**

Бухарестта ул татар телендә «Бүз егет» дигән китапта басылып чыкты. Дастанны филология фәннәре докторлары, илленче елларда Казан университетында белем алган Нәдрәт һәм Әнвәр Мәхмүт Румыниядәге татар авылларында язып алганнар. Әлеге дастанны язучы Флүс Латыйфи Казан әдәби татар теленә күчереп, 1993 елда аерым китап итеп чыгарды[2]. Бу вариант фәндә Чура батырга багышланган татар дастанының Румыниядә яшәүче Добруджа татарлары варианты дип санала[3]. Әсәр хакында филология фәннәре докторы Лилия Мөхәммәтҗанова болай дип яза: «Дастан нугай версиясендәге күләмле генә бер вариант белән шактый охшаш. Әмма чынлыкта Ф. Латыйфи, дастанның берничә халыктагы версия-вариантларын файдаланып, үзебезнең телдә яңа бер вариант барлыкка китергән»[4].

Дастанның Румыния варианты минә кайсы ягы белән кызыклы: аның теле әле бүгенге көндә дә Казан татарларына яхшы аңлаешлы. Димәк, төрле-төрле

[2] Латыйфи Ф.Ф. Чура батыр. Татар халык дастаны / хәзерге әдәби телгә күчерүче Ф. Латыйфи. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 87 б.

[3] Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос: книжные дастаны. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. – С. 229.

[4] Мөхәммәтҗанова Л.Х. Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – Б. 135.



«Чура-батыр» дастанына иллюстрация.
Рәссам Р. Шәмсетдинов.
Фоторәсем millattashlar.ru интернет чыганагыннан алынды



«Чура Батыр» дастанына иллюстрация.
Фоторәсем millattashlar.ru интернет чыганагыннан алынды

мәмләкәтләрдә яшәсәләр дә, татарның уртак теле, уртак авыз иҗаты, уртак гореф-гадәтләре һәм йолалары булган. Безнең борынгы тарихыбыз уртак. Дастан ерак бабаларыбызның йолалары, гадәтләре, кием-салымы, сугыш кирәк-яраклары, яшәү рәвеше хакында бай мәгълүмат бирә.

«Чура батыр» дастаны халык тормышын, аянычлы язмышын, аның милли йөзен тасвирлый торган күләмле әсәр. «Чура батыр» дастаны бер үк вакытта берничә төрки халыкның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итә. Хәзерге вакытта



«Казанны алу».
Рәссам Ф. Халиков



**«Кол Шәриф мәчете янында соңгы сугыш». Рәссам Ф. Халиков**

әлеге дастанның казан, кырым татарлары, нугай, казакъ, башкорт, каракалпак һәм кыргыз халыкларында табылган 25 варианты мәгълүм[5]. «Чура батыр» дастаннарының кайсы халыкның нинди генә варианты булуына карамастан уртак сюжеты – татар ханлыкларының бер-бер артлы рус дәүләте тарафыннан буйсындырылу вакыйгасын тасвирлый.

«Чура батыр» дастанының татар варианты шактый үзенчәлекләргә бай булуы, аның реаль вакыйгаларга да иң якын торган версия булуы белән аерылып тора. Бу аңлашыла да, чөнки Казан ханлыгының Мәскәүгә көчләп буйсындырылуы, иң беренче нәүбәттә, татар халкы өчен зур фаҗига булган бит. Бу әсәр Идел буендагы Казан шәһәренең рус дәүләте тарафыннан яулап алыну вакыйгасына бәйле авыр күренешләр һәм шушы чор шәхесләре, каһарман батырлары хакында сөйли. Ә Казан шәһәре, мәгълүм булганча, 1552 елда яулап алынган, шулай булгач, Чура батыр турындагы бу мәшһүр дастаннар XVI йөз уртасыннан соңгы чорга карый.

Татар халкының эпик иҗатында Чура батыр образына багышланган әсәрләрнең барысында да ике зур тема ачык тасвирлана, алар – каһарман Чура язмышы һәм Казан җимерелү вакыйгасы. Дастанның татар варианты мондый сүзләр белән тәмамлана:

*«Соңра урыс гаскәре галиб булып,*
*Казан шәһәрен алды.*
*Урыс падишаһына табигъ булдылар.*
*Бу Казан шәһәрен алганнан бер ел соңра*
*Хаҗитархан шәһәрен янә алды.*
*Чура батырның хикәяте тәмам булды»*[6].

Чура батырга багышланган эпос – тарихыбызның кыйммәтле бер өлеше, үткәннәребезнең онытылмас кайтавазы, тәрбияви һәм мәдәни рухи байлык. Бу бөек ядкарь төрки халыклары өчен генә түгел, ә гомумән дөнья эпосына торырлык фәнни, тарихи зур мирас. Эпос-дастанда, гомумән, фольклорда халыкның чын милли аңы саклана. Чура батыр образы – фольклорда төрки халыкларның үзара якынлыгын, туганлыгын күрсәтеп тора торган бер дәлил.

[5] Ибраһимова Л.Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. – Казан: «Фикер» нәшрияты, 2002. – 190 б.

[6] Татар халык иҗаты. Дастаннар // Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр язучы Ф.В. Әхмәтова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 380 б.

# ТЫЮЛАР

## борынгы яшәү кануннары

*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*



**Мифологиядә тыюлар жанры бар. Аны күзаллау өчен халык телендә булган бер тыю берәмлеген искә төшерү дә җитә: «Яңа йортка күчкәч, беренче кырык көндә ялгыз кунарга ярамый» (бастырыласың).**
**Бу тыюның борынгылыктагы ышану-риваятьләрен тулысынча тасвирлау мөмкин булмаса да, аның мифологик тарихын күзаллау кыен түгел: кырык көн эчендә ялгыз кунган кеше янына шайтан кереп кала, аны җен алыштыра яисә албасты баса.**

Тыюлар әлегә аз өйрәнелгән. Моның сәбәбе дә бар. Сер түгел, еш кына тыюларның авыз иҗатындагы яисә кульъязма һәм басма әдәбияттагы чыганакларын билгеләү кыен, икенчедән, ул берничә жанр очрашкан урында, дөресрәге, берничә жанрның кыйпылчыкларыннан оешып формалаша. Кайчакта ул төп миф-риваятьнең әчтәлеген генә тәшкил итә, еш кына зур мифның бер образлы детале, гыйбрәтле фәлсәфәсе рәвешендә килеп ирешә. Ләкин һәр очракта да шул аңлашыла: миллләт үзенең мең еллык тарихында әлегә ныклап аңлашылып та җитмәгән дөнья барышының, табигатьнең, кешелек яшәешенең хорафатларыннан, авыруларыннан, шаукымнарыннан саклану ысуллары эзләгән, шул рәвешле тыю кагыйдәләре булдырган.

Мифологик мирасның әхлак һәм йола кагыйдәләренә нигезләнгән, тыюлар белән бәйле тәрбияви, фәлсәфи һәм магик ышанулар системасы борынгылыктан башлап хәзерге көннәргә кадәр үзенчәлекле яшәү кодексын тәшкил итә.

Аерма шунда гына: борынгылыкта һәр тыю яисә юрамыш артында миф, риваять, ырым-ышану, йола фәлсәфәсе торса, һәм бу миф-риваятьләрне халык яхшы күзаллаган булса, бүген инде без күпчелек тыюларны юрамыш, ырым-ышану яисә йола тәгълиматы белән тәгәл генә аңлата да алмыйбыз (мәсәлән: «Балаларга күмер ашатырга ярамый» (бу бала кыска гомерле була), «Баланы куянга охшатырга ярамый» (үлә), «Күршедән балта алып торганда, иңбашка салып чыгарга ярамый» (балта алган өйдән мәет чыга) һәм башкалар.

**Әлбәттә, тыю янында тиешлек (зарурлык) тә булырга тиеш. Әйтик, без «Иртән торганда сул аякка басарга ярамый» дибез икән, бу, чынлыкта, «Йокыдан торгач, уң аякка басарга кирәк» дигән сүз була...**

Чынлыкта, безнең тормышыбыз тоташ тыюлардан тора: нәрсә эшләргә ярамый, нәрсә тыела; кайбер гамәлләр хәтта үлем, һәлакәт белән тиңләнә... Яшәешебезнең кайсы ягын гына алып карасак та, без шундый бер гыйбрәтле кисәтү белән очрашабыз: «Яңакка таянып утырырга ярамый» (атаң-анаң үлә), «Мунчага үзеңне белдермичә (исәнләшмичә, тамак кырмыйча) керергә ярамый» (ис тиеп яисә буылып үләсең, мунча иясе буа, мунча җеннәре зиһенеңне ялгыштыра), «Ризык өстенә утырырга ярамый» (арт саның корыша), «Тозны түгәргә ярамый» (йортта дуслык, татулык бетә), «Балага узган (корсаклы) хатын-кызга кичен су буенда йөрергә ярамый (баласы гомерлек авыру булыр; гомере буе ялгыз яшәргә күнеккән Су анасы, көнләшеп, зәхмәтле сихерен җибәрә; аннары: кара ияләр, түбән рухлар кичкә (төнгә каршы), гадәттә, «пәри туйлары» ясарга су, яр буйларына җыелучан булалар) һәм башкалар.

Әлбәттә, тыю янында тиешлек (зарурлык) тә булырга тиеш. Әйтик, без «Иртән торганда сул аякка басарга ярамый» дибез икән, бу, чынлыкта, «Йокыдан торгач, уң аякка басарга кирәк» дигән сүз була... Ләкин, барыбер, яшәү тәҗрибәсенең нигезендә иң элек тыю, кисәтү ята, ул беренчел әһәмияткә ия, аннары гына тиешлек, зарурият. Әйе, элек-электән шулай килгән: тормышта тыю, тыелу, ягъни яшәеш кысалары, тормыш һәм йола кануннары һәрчак мөһимрәк булган. Тыелмаган гамәлләр рөхсәт ителгән, әлбәттә, моны һәркем аңлаган, ләкин, ата-бабаларыбыз, нәрсә генә эшләсәләр дә, кылган гамәлләренә бик сак килгәннәр. Инде шикләнә калсалар, еш кына ата-бабадан калган ышанулардан яисә Ислам тәгълиматыннан, Коръән сүрәләреннән һәм хәдисләрдән җавап эзләгәннәр.

Тыюлар икенче бер очракта юрамышлар белән тыгыз бәйләнеп килә, хәтта юрамышларның бер кисәген тәшкил итә: «Артың белән йөрсәң – атаң-анаң үлә» (артың белән йөрергә ярамый, димәк), «Айга бармак белән төртеп күрсәтсәң – атаң-анаң үлә» (айга бармак белән төртеп күрсәтергә ярамый, димәк) һәм башкалар. Инде төртеп күрсәткән очракта, ничек бу хәлдән чыгарга кирәге дә билгеле: бармакны тешләргә кирәк. Авыр хәлдән (тыелган әйберне эшләгәннән соң) чыгу юлларын башка тыюлардан да чамаларга мөмкин. Әйтик, «Кеше (кунак) киткәч, идән себерергә ярамый» дигән тыю бар. Инде онытылып, кунактан соң идән себереп куйгансың икән, шундук бу тыюны «капларлык» икенче гамәлне башкару теләге туа һәм, үзең дә сизмәстән, идәнне түргә табан себерә башлыйсың (борынгылар да шулай эшләгән). Ләкин шунысы да бар: бу гамәл бары тик моңа кадәр булган тыюлы гамәлне «кире кайтару» өчен генә эшләнә. Тик торганнан гына ишектән түргә табан идән себерү, чынлыкта, начарга юрала.

Әйе, нәкъ шулай: кеше тормышында никадәр эш-гамәл бар, шулкадәр тыю бар. Чөнки һәр гамәлнең үз кануны бар, димәк, тыелган өлеше, рөхсәт ителгән өлеше бар. Шуңа күрә тыюларның саны-исәбе юк. Шәхсән үзем, ышанулар белән бәйле мәдәни мирасны күзаллап чыкканнан соң, борынгылыктан ук яшәү кануннарына, табигатьне аңлау, кабул итү, аның белән компромисста яшәү тәгълиматына әверелгән биш меңнән артык тыю берәмлеге терки алдым. Һәр тыю артында миф, риваять, йола торуын исәпкә алсак, бу рухи мирас нигезендә татар рухияте өчен мөһим булган күпме миф (мифологик текст) ятканын ачыклау кыен булмас. Киләчәктә тыю белән бәйле бу миф-риваятьләр фондын бастырып чыгарырга да кирәктер дип саныйм.

Әйтүебезчә, хәзер еш кына тыюларның борынгылыктан килүче ышану-мифлар белән бәйле булуын раслау да кыенлаша бара. Ислам дине, шәригать кануннары белән кабул ителгән, хәдисләр

белән дәлилләнгән тыюлар, мәҗүси тыюлар белән керешеп, йола ягыннан да, мәгънәви яктан да көчәеп, кешенең аңына, рухиятенә һәм табигатенә тагын да ныграк тәэсир итә башлый. Бу очракта дини факторны да, милли факторны да истә тотарга кирәк. Һәр халыкның, һәр милләтнең үз рухияте, үз тарихы, үз язмышы дисәк тә, безнең татарлар төрки-татар рухи мирасына таянып һәм шул ук вакытта Ислам кануннарына инанып үз тормышын кора, язмышын булдыра. Ләкин бүген телдә очраган тыюлар арасында безнең өчен чит-ят булганнары да очрап тора, билгеле инде, алар башка мифологик системалардан яисә әхлакый кануннары какшый башлаган көнбатыш мәдәниятеннән килеп кергән. Бер генә мисал. Бүген яшьләр арасында еш очрый торган «Кеше аягына басарга ярамый, бассаң, димәк ки, син аны очрашуга чакырасың» дигән ышану бар. Ә бит безнең ата-бабалар телендә аның чын, тарихи варианты булган: «Кеше аягына басарга ярамый – атаң-анаң үлә». «Җәяүле дәверләр»дән килүче бу тыю (юрамыш) шул хакта кисәткән: кеше өчен иң мөһиме – аякны саклау, аяк исән икән, димәк, тормыш бар, юл бар, ризык бар... Аякны авырттыру, зәгыйфьләндерү, чынлап та, борынгылар өчен үлем белән бер булган. Шуңа күрә дә борынгы кеше башка кеше аягын таптауны иң соңгы чиккә җитеп тыйган, – бу гамәлне ата-ана үлеме белән тиңләгән.

Ә хәзер, хөрмәтле укучылар, тормышыбызда еш очрап торган, борынгылыктан ук килүче кайбер тыюларны сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Безнең карамакта тыюлар белән бәйле иллегә якын (йорт-өй, йорт-хуҗалык, абзар-мунча, ризык-тәгам, юл-сәфәр, зират, үлем-китем, бала-чага, кунак каршылау-озату, ир-хатын, туй-никах, кияү-килен, табигатькә бару, авырулар белән бәйле һәм башка) тема бар. Монда журнал укучыларына кызык тоелырдай берничә темадан кайбер тыю кагыйдәләре белән чикләнәбез.

«
**Һәр халыкның, һәр милләтнең үз рухияте, үз тарихы, үз язмышы дисәк тә, безнең татарлар төрки-татар рухи мирасына таянып һәм шул ук вакытта Ислам кануннарына инанып үз тормышын кора, язмышын булдыра.**
«

## ӨЙ, ЙОРТ-ҖИР ТЫЮЛАРЫ



– Яңа салган өйдә кырык көнгә кадәр ялгыз ятарга ярамый (бастырыласың).

– Яңа йортка беренче теләсә кемне кертергә ярамый (яки ул иң өлкән кеше булырга тиеш (өй хуҗаларының гомере озын булсын, димәктән), яки иң күп балалы кеше булсын (бу йортта балалар күп булсын, димәктән), яки бер гөнаһсыз сабый бала булсын).

– Түшәм өстендәге туфракны яңартып салырга ярамый (үлек чыга). «Тиң – тиңен, туфрак туфракны тарта» дигәннәр.

– Тәрәзә төбенә яки ишек тупсасына утырырга ярамый (үсмисең).

– Тупсага баскан бала да үсми.

– Ишек аркылы, тупса аша күрешергә ярамый (кулың корый).

– Ишек аркылы әйбер алырга ярамый (бәла килә, кулың корый).

– Тәрәзә төбенә утырырга ярамый (фәрештәнең канаты тала).

– Өй нигезенә тибәргә, сугарга ярамый (нигез корый).

– Тәрәзә аша йөрергә ярамый (тәрәзә аша йөргән малайларның-кызларның хатыннары, ирләре карак була).

– Өй эчендә бура калдырып йорт салырга ярамый (бу йорттан үлем китми; бура кабергә тиңләнә).

– Тәрәзәне чатнатырга, ватарга ярамый (бу йортка бәла чакырасың; тик торганнан чатнаса – бу йортка күз тигән, яисә хуҗасына күз тигән).

– Морҗа кирпечени кагылырга, бигрәк тә аны куптарырга ярамый (өйдән җылылык китә, татулык-бәхет китә).

– Матча астына карават куярга, бишек эләргә ярамый (матча – җеннәр биләмәсе).

– Кичтән, ишек ачып, өйгә мәче кертергә ярамый (шайтан керә).

– Өйгә кергәндә, бусагага басып керергә ярамый (атлап керергә кирәк, юкса өстеңнән сүз китмәс).

– Тәрәзәдән сөяк ташларга ярамый (яшен керер).

– Йорт бурасына күк төстәге усак агачы кертергә ярамый (йортта шайтаннар булачак).

– Нигез балчыгын кешегә бирергә ярамый (йортың таркала).



## ЮЛ, СӘФӘР ТЫЮЛАРЫ

– Кемне дә булса юлга озаткач, буш кул белән керергә ярамый (ул кешенең юлы уңмый).

– Кемне дә булса юлга озатыр алдыннан өй җыештырырга, идән себерергә, табак-савыт шалтыратырга ярамый (ул кешенең юлы хәвефле була яисә ул кеше тузынып кайтыр).

– Юлга кеше озаткач, ихата, капка алды себерергә дә ярамый (тузан туздыру ызгыш-талашка юрала).

– Юлга кузгалганда бер өлеш ризыгыңны калдырырга онытма (ризыгың тартып торыр, исән кайтырсың, дигәннәр).

– Бала елаган йорттан сәфәргә кузгалырга ярамый (бала тынычлангач кына юлга чыгарга).

– Юлга чыгар алдыннан бер пар чиләккә мөлдерәмә итеп су тутырып куярга онытма (шулай итсәң – юлың уңачак).

– Юлга чыгар алдыннан тәрәзә өлгеләрен юарга (сөртергә) онытма (юлың уңар, исән-сау йөреп кайтырсың).

– Юлга чыгучы матчага икмәк кисәге кыстырып калдырырга тиеш (ризыгы чакырып торачак, исән-сау кайтарачак).

– Юлга чыкканда үбешеп китәргә ярамый (исән-сау кайтмавы бар).

– Юлыннан исән-сау кайтырга ниятләгән кеше үз баласы яткан бишекне өч мәртәбә урап чыгарга онытмасын.

– Юлга чыкканда су юлы буйлап барудан тыел (буш чиләк белән очраулары бар, ә буш чиләк – уңышсызлыкка).

– Юлга чыкканда бик кирәкле әйбереңне онытырга ярамый (юлың уңмаячак).

– Сәфәргә чыккан кеше күрешеп китәргә тиеш түгел (күрешмичә киту – әйләнеп кайтып күрешүгә, димәктән).

– Юлга чыкканда киемеңне кагарга ярамый (юлың уңышсыз була).

– Юлга кузгалган кеше артына борылып карамасын (борылып караса – әйләнеп кайтмас, дигәннәр).

– Юлга чыкканда этка ризык бирмичә китмә (бирсәң – юлың уңачак).

– Юлга чыкканда җирдә яткан себеркене атлап чыгарга ярамый (афәткә юлыгырсың). Кайбер якларда: көянтәне атлап чыгарга ярамый.

– Юлда барганда таш, балчык кисәкләрен типкәләп барырга ярамый (бәла чакырасың).

– Юлда барганда юл буендагы агач-куакларны, үлән-чәчәкләрне сындырырга, өзәргә, кошларга таш атарга ярамый (аларның Юл иясе, Юл фәрештәсе булуы бар).

– Юлда төкеренеп барырга ярамый (авырыйсың).

– Юлга чыкканда сул аякны атлап кузгалырга ярамый (уң аягың белән атлап кузгал).

– Юлга чыкканда эт юлыңны аркылы чыкса – уңышка; мәче аркылы чыкса – уңышсызлыкка (мәче юлыңны киссә, юлга чыкма; кире борылып кайтып, юлга кабат кузгалуың мәслихәт).

– Берәр кешене озатканда артыннан озак карап торырга ярамый (озак кайтмавы бар).

– Сәфәргә чыгар алдыннан яратмаган кешең килеп керсә, юлга чыкма (ул чыгып киткәч, кабат ризык җыйгач кузгалырсың).

– Юлга хәлсез, бозык ат һәм иске, ватык арба-чана белән чыкма (юлда ат туарылса – бәлага, уңышсызлыкка).

– Юлга кузгалганда салкын су эчеп чыгарга ярамый (салкын каршы алачаклар).



## РИЗЫК, ТАБЫН ТЫЮЛАРЫ

– Ашый торган сыныгыңны ашап бетермичә этка бирергә ярамый (йөрәгең авырулы була).

– Ризыкны урлап ашарга ярамый (очкылык тотып интектерәчәк).

– Ризыкка каплаган ашъяулыкка кулны сөртергә ярамый (нахак сүз, авыр гайбәт сүзе ишетәсең).

– Ризыкны таптарга ярамый (аягың корыша, буыннарың зәгыйфьләнә).

– Бер бөртек ипи валчыгын да таптарга ярамый (бер бөртек ипи валчыгы бер еллык гомереңне кыскарта. Монда «Бер тары бөртеге кадәр ипи бер кешедән зур», «Бер ипи валчыгы мәчеттән зур» дигән әйтемнәрне искә төшерергә туры килә).

– Икмәкне китап, бигрәк тә Коръән өстенә куярга ярамый (Коръән икмәктән югары).

– Көйгән ризык ашарга ярамый (әйтем: «Көйгән көекле булыр»).

– Офыкта кояш батканда кулдан төшеп киткән ризыкны ашарга ярамый (ул сиңа авыру эзләп төшкән булыр).

– Эчә торган сөтне яисә кымызны савыт төбендә калдырырга ярамый (сыер яисә бия кысыр кала).

– Аш өстенә таба ябарга ярамый (андый ашны ашаган кеше бирән булыр).

– Табында валчык калдырырга ярамый (табындагы валчыкны ашасаң, хур кызларына мәһер була, имеш).

– Тәлинкәдә ризык, аш калдырырга ярамый (бәхетең кала).

– Елга бер мәртәбә булса да умач ашамый калырга ярамый (бигрәк тә туган көндә; «Умач (Умай-аш) җелеккә китә» дигән сүз бар).

– Чи ярма ашарга ярамый (фәкыйрьлеккә).

– Ипинең башын сындырып ашарга ярамый (йорт башына (хуҗасына) авырлык килер).

– Мичтән икмәкне алгач, утын салмый (куймый) калдырырга ярамый (мал кысыр кала, дип утын салып куялар).

– Ашамлык, эчемлек яки су салынган савытны төнгә каплап куймасаң – шайтан керә (шайтан аягын яисә койрыгын тыгып чайкый, пәри ялый дип тә әйтәләр; мондый савытка аркылы чыра булса да куярга кирәк).

– Чит ризыкка кызыкма (бөтенлек, муллык китә).


– Кеше үлгәндә өйдә калган ризыкларны, ашларны ашамыйлар («кан чәчрәгән» диләр; борынгы ышану буенча, кеше җан биргәндә, өйдә тездән кан була, имеш. Кешеләр йөргәндә бу кан чәчрәп-чәчрәп китә икән, азык-төлек, түшәкястык буяла икән. Шуңа күрә, кеше җан биргәндә, кан чәчрәмәсен дип, өйдәге бар ашамлыкны, урын-җирне җыеп алалар, каплап куялар).

– Ашъяулыкны бөркәнергә ярамый (гаиләдә ызгыш чыга).

– Өстәл почмагына утырып ашарга ярамый – җиде ел кияүгә чыкмыйсың (өйләнмисең) яисә авырыйсың дигән тыю нигезендә шайтан белән бәйле ышану ята. Мәгълүм булганча, шайтаннарның яраткан яшәү урыны почмаклы урыннар, шуңа күрә өстәл почмакларында да алар бар. Почмакка утырган кешене (бигрәк тә балигъ булган яшь җилкенчәкне) алар бик тиз сихерли алалар. Ни өчен җиде ел соң? Җиде – шайтаннар өчен куркыныч сан. Җиде елдан соң «шайтан зәхмәте»нең көче бетүчән була.

– Казан өстеннән ашарга ярамый (фәкыйрьлек килә).

– Чәйне түгеп эчәргә ярамый (киявең исерек була).



## САБЫЙ БАЛА ТЫЮЛАРЫ

– Баланы беренче мәртәбә бишеккә салганда аның үзен генә салырга ярамый (аңа кадәр бәләк яки тукмак салсаң, бала таза-сау була. Шуңа күрә дә борынгылар баланы, яшерен тел белән «тукмак» дип йөрткәннәр.

– Буш бишекне тирбәтергә ярамый (бала елак исә авыру була).

– Баланы бишектә ялгыз калдырырга ярамый. Бигрәк тә беренче кырык көндә (җенпәри (шайтан) алыштыра, бала авырый башлый, бозыла).

– Бишектәге балага көзге белән уйнарга ярамый, гомумән, бала көзгегә карарга тиеш түгел (зиһене зәгыйфьләнә яисә сакау була).

– Бала кырык көнгә кадәр ана сөте белән генә тукланса, әйбәткә юралган (бу очракта ул гомере буе анасы яныннан китми, аның тирәсендә бөтерелә).

– Бала керен тукмак (бәләк) белән тукмап юарга ярамый (бала имгәк яисә елак була).

– Бер яше тулмыйча баланың тырнагын кисәргә ярамый (киссәң, бала чирләшкә була).

– Баланың бер яшенә кадәр аның күлмәгенең эчке ягын әйләндереп юарга ярамый (баланың тәненә ит кунмый, имеш, ул зәгыйфь, авыру була).

– Кырыгына кадәр баланың чәчен пәке белән алырга ярамый (таз була).

– Баланы ут белән уйнаудан тыярга кирәк, гомумән, утка озак карап торудан тыярга кирәк (ут белән уйнаса, бала сигәк була, утка озак карап торучан баланың зиһене тиз зәгыйфьләнә).

– Бала атасының сакалы, гомумән, йөз бите белән уйнарга тиеш түгел (ул атасының башына уйный).

– Балага аяк селкеп утырырга ярамый (шайтан яисә җен-пәриләр иялләшә, алар таган атынырга ярата бит).

– Баланың кендеген югалтырга ярамый (явыз булып үсә).

## ТОРМЫШ-ЯШӘЕШ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТЫЮЛАР



– Кара болытлы көнне, яшен вакытында мунчага керергә ярамый (яшеннән курку, пәриләр сиңа сыеналар да, яшен суга. Яшен «җенгә сугам» дип суга икән).

– Атна кич тырнак кисәргә ярамый (эт тырнагы чыга).

– Кич белән тырнак кисәргә ярамый (гомерең кыскара).

– Кич кешегә акча бирергә ярамый (бәхет китә).

– Кояш баеганда йокларга ярамый (бәхетең кими).

– Кулны югач, юеш килеш селкергә ярамый (шайтан ярала).

– Сишәмбе көнне юлга чыгарга ярамый (уңышлы булмый).

– Суга сокланып карарга ярамый (тота). «Бу су салкын икән, каты икән» диярргә кирәк.

– Утка төкерергә ярамый (авызың кутырлар).

– Юынмыйча ятарга ярамый (юынмасаң, төнлә шайтан ялый).

– Һавада йолдыз атылганда күккә карарга ярамый (җиргә карарга кирәк, юкса бәхетең атылыр).

– Давыл чәчәген өзәргә ярамый (давыл чыгар).

– Кияүгә киткән кызга гөл бүләк итәргә ярамый (гөл белән туфрак китә). Чит-ят җиргә дә үз гөлеңне бүләк итәргә ярамый.

– Ут чәчәген өйгә кертергә ярамый (янгын чыга).

– Балык тоткач, санарга ярамый (бәрәкәте бетә).

– Күгәрченнең йомыркасын алырга, оясын туздырырга ярамый (йорт түбәсенә ут ташлап китә икән).

– Тавык миен ашарга ярамый (урманда адашасың).

– Су агымы ягына каз-үрдәк сатарга ярамый (токымын алып китә).

– Кояш баегач, сөтне кешегә бирергә ярамый (сыерның сөте кими).

– Ашаган вакытта киерелергә ярамый (үсми каласың).

– Кеше кулындагы сөялне санарга ярамый (үзеңә чыгар).

– Хатын-кызга үрелгән толым өстеннән чәч тарарга ярамый (иреңнең сөяркәсе булачагын көт тә тор).

– Ашаган сыныгыңны калдырма (иптәшең ташлар).

– Баш киемен, мунчала итеп, идән юарга ярамый (башың түбәнчелеккә төшәр).

– Берәр җиргә барырга чыккач, кире кермә (юлың уңмас, бу очракта көзгегә карап, бит сыпырып, чәч тарап чыгарга кирәк; кайбер төбәкләрдә, тоз кабарга кирәк, диләр).

– Күмер таптарга ярамый (нахак сүз ишетерсең).

– Көзгегә карап җырларга ярамый (сүз ишетерсең).

– Савыт-саба шылтыратырга ярамый (тавыш чыга).

– Киемеңне сул ягы белән төреп куярга ярамый (бәхетең киреләнеп килми торыр).

– Эскәтергә бит сөртергә ярамый (битеңә оят килер).

– Өйдә сызгырырга ярамый (янгын чыга); тышта сызгырсаң – җил чыга, шайтан килә. Акча, байлык китә, дигән ышану да бар.

– Өстәл өстен кул белән яисә кәгазь белән сөртергә ярамый (йортта тавыш чыга).

– Иләк аша карарга ярамый (киявең шадра булыр).

– Өстәл сөрткәндә, чүп яки ипи валчыгы калдырырга ярамый (бу очракта да киявең шадра була).

– Чүп өстеннән чыгарга ярамый (өстеңә начар сүз әйтәләр).

**Чит җирләргә барып чыгып, андагы кешеләрнең ничек яшәгәнен беләсең килсә, театрын барып күр, диләр. Чөнки театр – ул тормыш көзгесе, яшәеш, искиткеч могҗиза. Театрның йөзек кашы – аның артистлары. Бүген сүзем әнә шул йөзек кашларының берсе һәм, минем карашка, иң затлысы хакында. Ул Кибәченең яшел хәтфә болыннарында тәгәрәп үскән, чирек гасырдан артык гомерен татар театры сәнгатенә багышлап, 100гә якын образ иҗат иткән, бүгенге көндә Чаллы драма театрында хезмәт куючы авылдашыбыз – Татарстанның атказанган артисты Илфат Әскәров.**



# ИЛФАТ ӘСКӘРОВ – «КИБӘЧЕ ӘЛМӘНДӘРЕ»

**(«Минем тарих – минем Татарстан!» II Бөтенроссия бәйгесенә килгән эш)**



Алексей –
«Яратылмый калган ярлар»
(Б.Сәлахов)



Каракаш –
«Яшь аралаш көлү»
(Р. Батулла)



Якуп –
«Без китәбез, сез каласыз»
(Т. Миңнуллин)



Яшь Насыйбулла –
«Абага алмасы ачы була»
(Р. Сабыр)



**Кабан – «Бурлак» (М. Гыйләҗев)**

Илфат Әскәров 1973 елның 12 августында Саба районы Олы Кибәче авылында Мансур абый һәм Рушания апа гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Гаиләдәге башка балалардан үзенең җор телле, шаян-шук булуы белән аерылып тора. Олы Кибәчедә башлангыч белемне ала, укуын Төбәк сигезьеллык мәктәбендә дәвам итә һәм Икшермә урта мәктәбенә йөреп тәмамлый. 1991 елда Казан дәүләт сәнгать академиясенә укырга керә, танылган артистлар Илдар Хәйруллин һәм Наил Дунаевтан белем ала. 1996 елда дипломлы яшь артистны Чаллы татар дәүләт драма театры шатланып кабул итә.

Шул вакыттан бирле Илфат Әскәров әлеге театрның алыштыргысыз артисты. Уңыш арты уңыш казана: Туфан Миңнуллинның «Авыл малае» спектаклендә – Галимҗан, Мостай Кәримнең «Ай тотылган төн»ендә – Дәрвиш, Антон Чеховның «Дядя Ваня»сында – Астров, Рабит Батулланың «Яшь аралаш көлү» спектаклендә – Каракаш һәм башка рольләре өчен төрле театраль премияләргә ия була. Равил Сабырның «Абага алмасы ачы була» спектаклендә – яшь Насыйбулла, Рабит Батулланың «Яшь аралаш көлү» әсәрендәге Каракаш рольләрен театр белгечләре аеруча уңышлы дип бәяли.

**“Танылган драматург Туфан Миңнуллин, спектакльне карагач: «Чаллы театры Насыйбулла язмышын әйбәт итеп, сәнгатьчә күрсәтә белгән. Артистлар бик шәп уйный», – дип белдергән.”**

Танылган драматург Туфан Миңнуллин, спектакльне карагач: «Чаллы театры Насыйбулла язмышын әйбәт итеп, сәнгатьчә күрсәтә белгән. Артистлар бик шәп уйный», – дип белдергән. Күренекле язучы Факил Сафин: «...Насыйбулланың яшь чагын уйнаган Илфат Әскәров һәм Гөлия ролен башкарган Лилия Минһаҗева шулай ук тамашачыларны ышандырдылар. Насыйбулланың, 1953 елда авылга әйләнеп кайткач, Гөлиясе белән 13 елдан соң яңадан очрашып кочаклашуын тамашачылар дәррәү кул чабулар белән каршы алды. Димәк, алар тамашачыны шушы халәткә китереп җиткерә алдылар. Бу бик



зур осталык сорый торган әйбер, рольләрнең эпизодик икәнен искә алсак, бигрәк тә», – дип үз бәяләмәсен биргән.

Илфат абый бүгенге уңышын, героен ачып бирү сәләтен туган авылына һәм гомумән, авыл тормышына бәйләп карый. «Ниндидер персонажны уйнау өчен аның күзлегеннән тормышны күрә белергә кирәк, – дип, рольгә керү серләрен ача. – Миңа авылда яшәүнең файдасы тия торгандыр. Каһарманнарым да шундый – авыл тормышыннан алынган. Әйтик, безнең авылда да Марсель исемле Алла бәндәсе бар иде. Ул теләсә кем белән сөйләшми, үз дулкынында яши һәм хөрмәт иткән кешеләре белән генә аралаша. Мөслим районына кайтып йөрим – анда да Марсель исемле Алла бәндәсе бар. Дәрвиш образын шуларга карап тудырган идем».

Илфат Әскәров күп кырлы шәхес. Бөтен күңеле белән татар әдәбиятына, шигъриятенә гашыйк кеше – шигырьләрне, проза әсәрләрен үзенә генә хас аһәң, гаҗәеп осталык белән башкара.

Тырыш, үҗәт, шаян, җор телле бу артистта мин еш кына Әлмәндәр чагылышын күрәм. Әллә шул сыйфатларына карап, әллә яратып, үз итеп авыл халкы да аны «Кибәче Әлмәндәре» дип атый. Әйе, тормышны, табигатьне, яшәешне яратучы Илфат Әскәров андагы матур сыйфатларны үзенә туплаган, олы хөрмәт казанган шәхес.

Бөек шәхесләрне үз халкы тудыра, үстерә, аңа канатлар бирә, очышын борчылып һәм куанып күзәтә – зур шәхесләре булган халыклар, үз чиратында канатлы һәм мәңгелек. Безнең татар халкы үтә үзенчәлекле язмышлы, фаҗигале тарихы, яңарышка юл тоткан бүгенгесе һәм киләчәгенә өмете булган бер халык. Аның гали рухын, әле дә яшеренеп яткан бинигаһа көчен, мөмкинлекләрен күрсәтер җан көзгесе булган шәхесләребез бигрәк тә кирәк. Шөкер, алар бар.

Илфат Әскәров та татар театры сәхнәсендә балкучы Олы Кибәченең үз улы.

**Альмир БӘШӘРОВ, 15 яшь**
**(Житәкчесе – Илсөя Бәшәрова)**
**Саба районы, Олы Кибәче авылы**

**А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында И. Әскәров башкарган рольләрнең кайберләре:**

**Казначы – «Йосыф вә Зөләйха»** (Кол Гали);
**Брендавуан – «Саран»** (Жан-Батист Мольер);
**Панталоне – «Ике хуҗаның хезмәтчесе»** (Карло Гольдони);
**Доверенный – «Банкрот»** (Галиәсгар Камал);
**Хәлил – «Галиябану»** (Мирхәйдәр Фәйзи);
**Авыл егете – «Сүнгән йолдызлар»** (Кәрим Тинчурин);
**Вафа – «Кәләпүшче кыз»** (Гаяз Исхакый);
**Нурмый – «Нурислам нигезе»** (Рабит Батулла);
**Каракаш – «Яшь аралаш көлү»** (Рабит Батулла);
**Дәрвиш – «Ай тотылган төндә»** (Мостай Кәрим);
**Алмаз – «Кызлар, ишек ачыгыз!»** (Наил Гаетбай);
**Галимҗан – «Без бит авыл малае!»** (Туфан Миңнуллин);
**Кабан – «Бурлак»** (Мансур Гыйләҗев);
**Михаил – «Хәят»** (Равил Сабыр);
**Яшь Насыйбулла – «Абага алмасы ачы була»** (Равил Сабыр);
**Вазыйх Нәсыйхович – «Шәһәр. Нокта. Брежнев»** (Шамил Идиатуллин);
**Якуп Акчурин – «Без китәбез, сез каласыз»** (Туфан Миңнуллин);
**Җәвид – «Башыңа төшсә»** (Раффи Шарт).



# «Зәрә» бәйрәме

**(Сценарий)**

*Мәрьям ШӘЙХЕТДИНОВА,*
*югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы,*
*Кукмара, Кенәбаш авылы*

*(Бәйрәм буласы алан матур итеп бизәлгән, мәйдан уртасыннан читтәрәк, ике зур казанда ботка пешерү урыны әзерләнгән.)*

**1 нче алып баручы:** «Зәрә» – халкыбызның гасырлар буена яшәп килгән гореф-гадәтләрен, әхлакый кагыйдәләрен, йолаларын, халкыбызның рухи байлыгын саклап килгән милли бәйрәм.

**2 нче алып баручы:**

Бәйрәмнең күрке – «Зәрә» боткасы әзерләү. Вакыт чоңгылында югалмаган, үзенең тәменямен безнең көннәргә җиткерә алган быелгы «Зәрә» бәйрәме барыбызга да миһербанлык, ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге һәм искиткеч күп шатлыклар алып килсен!

**1 нче алып баручы:**

Игенчелек белән көн күргән халык өчен язгы чәчү – иң әһәмиятле, иң җаваплы чор. Игенче аны көтеп, әзерләнеп каршы ала, атларын карый, чәчү орлыгын барлый. Язгы сабан эшләре килеп җитәр алдыннан кешеләрне шушы җаваплы чорда үзара якынайта, хезмәткә дәрт өсти, бердәмлек уята торган төрле бәйрәмнәр, тылсымлы йолалар да күп. Аларның мәгънәсе киләчәктә иген уңышының муллыгын, ел фасылларының әйбәт булуын теләү, табигатьтән ярдәм көтү һәм башкага кайтып кала. Мәсәлән, «Зәрә» бәйрәменең, «Зәрә» боткасының төп мәгънәсе – язгы эшләр башланырга вакыт җиткәнлеген бөтен халыкка хәбәр итү, бердәмлеккә чакыру.

**2 нче алып баручы:**

«Зәрә» боткасы – сабанга чыгар алдыннан йорт саен ярма, май җыеп, тау башына менеп пешерә торган ботка. «Зәрә» кычкыру – сабанга чыгарга берничә көн кала балаларның сабанга чыгарга вакыт җитүен белдереп кычкырып йөрү йоласы.

*(Мәйдан уртасына оныгын җитәкләгән әби чыга.)*

**Онык:** Кара әле, әбекәй, яланнар кардан ачылган, кояш җылы нурларын сибә! Нинди ямьле! Әнә, каргалар да кайткан. Димәк, озакламый «Зәрә» бәйрәме булачак! (Кыз бала сөенә, әйләнә, сикергәли). Әбием, ә нигә бу йоланы, «Зәрә» бәйрәме дип атаганнар? Гомумән, «Зәрә» дигән сүз нәрсәне аңлата?

**Әби** *(уйланып)***:** «Зәрә» төшенчәсе ерак скиф заманнарына бары тоташа, ди галимнәребез. «Зәрә» – «орлык» дигәнне аңлата. Кешеләр табигатькә булган мөнәсәбәтләрен борын-борыннан йолалар, гореф-гадәтләр аша чагылдырганнар. Алар ярдәмендә югары көчләргә мөрәҗәгать итеп, үз тормышларына җиңеллек, уңыш сораганнар. Игенчелек, терлекчелек белән көн күргән халкыбыз язга һәрвакыт зур өметләр баглаган. «Зәрә» бәйрәме яз килүенә, тереклекнең уянуына шатлык белдерү ул.

**Онык:** Әбием, ә менә иң беренче «Зәрә» бәйрәме безнең Кенәбаш авылында кайчан булган икән?

**Әби:** Моны берәү дә белми, кызым. Авылыбызның тарихы Петр I чорына барып тоташа һәм ул XVII гасырның ахырларына, XVIII гасырның башларына туры килә. Авылыбызга, Петр I указы белән, бакыр ятмаларын эзләргә җибәрелгән эшчеләр нигез сала. Алар өчәү – Балтач, Зәбир, Сөтимгән булган. Менә шушы бабаларыбыздан киткән инде авылыбызның тарихы. Шул чорларда ук башланган булса кирәк бу йола.

Элек-электән «Зәрә» бәйрәменә бөтен авыл халкы җыелган: яше-карты, бала-чагасы матур итеп киенеп, яландагы бәйрәмгә килгән. Ботка пешкәнче, уйнап-җырлап, көлешеп-юанышып алганнар. Безнең авыл халкы бик юмарт, кунакчыл халык булган, килгән бар кунакны ботка белән сыйлаган.

**Оныкː** «Зәрә» боткасын икенче төрле «Карга боткасы» да диләр, әйеме әбием? Ә каргалар бу бәйрәмне белә микән?

**Әби** *(көлеп кызның аркасыннан сөя)*: И, балакаем… Каргалар беләме, юкмы, монысы мөһим түгел. Җир-анага, табигатькә ихтирам йөзеннән бу йола. Киләчәк буын да күрсен, бергә-бергә, дус-тату, аралашып яшәсеннәр, бәйрәм итә белсеннәр, сабан эшләре башланганчы бер җыелып алсыннар, дигәннәр ата-бабалар. Ә каргалар, беләләр инде... Бар, кызым, дусларыңа әйт, киләсе якшәмбедә, көннәр аяз торса, «Карга боткасы» оештырыйк.

**Оныкː** *(сөенеп)*: Канатларым булса, карга кебек, очып кына урар идем авылны. Әйтәм, дәү әни, очам гына.

*Мин карга, кар-р-кар-р,*
*Тиздәнэреп бетәр кар,*
*Иңнәремдә канат бар,*
*Буең җитсә тартып ал.*

*(Очкандай, кулларын җилпеп, чыгып китә.)*

**Әби** *(уйланып)*: И-и, гомерләр… Әле кайчан гына мин дә шулай җилкенеп, Кенә елгасы яланында яланаяк йөргән идем... Аннан бирле ничә дистә еллар үткән. Ә күмәк җыелып ботка пешерү йоласы безнең Кукмара районының Кенәбаш авылында дәхшәтле сугыш елларында да үткәрелеп килгән, һаман да саклана.

*(Мәйданга бер төркем балалар чыга.)*

**1 нче бала:**
Ботка пешәр казанда
Тәмле ис таралыр урамда.

**2 нче бала:**
Әйдә, өйләргә барыйк,
Ризыклар җыйыйк.

**Бергәләп:**
*Зәр-зәр зәрәгә*
*Иртән торып бирсекөнгә Сөрәнгә!*
*Абыстайлар-түтәйләр,*
*Чыгарыгыз күкәйләр!*

**Әби:** Балалар, килегез, иң беренчеләрдән булып үзем капчыгыгызга ярма салыйм әле. Дөньялар тыныч, игеннәр мул булсын! Менә сезгә тоз, он, май, сөт, йомырка, ярма...

*(Әби мөнәҗәт әйтә.)*

*Изге авыл җирлегендә*
*Муллык, бәхет телик бергә.*
*Хәер, дога кылып сезгә.*
*Туган җирем нурга тулсын.*
*Ярмалы җир сабан көтсен,*
*Игеннәре шаулап уңсын,*
*Дәррәү эшләү, тату яшәү*
*Барыбызга насыйп булсын.*
*Балаларга тәүфыйкъ бирсен,*
*Табигатькә рәхим-шәфкать.*
*Туган җирдә күмәк яшик,*
*Югалмасын изге йола.*
*Борынгыдан калган йола –*
*Зәрә боткасы пешерү.*
*Гасырларга дәвам итсен,*
*Яшь буынга сабак булсын.*

**Балалар бергәләп:** Рәхмәт, Ак әби! Шулай булсын!

*(Өй янына килеп туктыйлар.)*

**1 нче бала:**
*Өйдәме түтәй?*
*Бир, зинһар, күкәй.*
*Бирсәң безгә өч күкәй,*
*Тавыгың салыр йөз күкәй.*

*(Ике хатын-кыз, бер ир-ат чыга. Кулларында төрле ризыклар.)*

**1 нче хатын-кыз:** Сөбханалла, балалар! «Зәрә» боткасына ризык җыясыз икән. Менә сезгә ярма, сөт. Дөньяларыбыз имин, тәннәребез таза булсын.

*(Чиләккә азык-төлек сала.)*

**2 нче бала:**
*Кызганма күкәй,*
*Май кирәк, ярма кирәк,*
*Зәрә боткасына бар да кирәк.*
*Тагын, булса, он чыгар,*
*Пешерәбез без чумар.*

**Балалар:** Рәхмәт сезгә, юмарт хуҗабикәләр!
**2 нче хатын-кыз:**
*Менә сезгә йомырка, май.*
*Бар да булсын җай-җай.*
*Игеннәр мул булсын,*
*Башаклары тук булсын.*
*Халык тазалыкта, татулыкта яшәсен.*

*(Азыкны чиләккә сала.)*

**Балалар:** Рәхмәт!
*Хай-хай-хай диләр,*
*Гали абзыйны бай, диләр,*
*Май өстенә сөт, диләр,*
*Сөт өстенә май, диләр!*

**1 нче ир-ат:** Менә, балалар, дөге ярмасы, сөт. Илләр тыныч булсын! Һәммәбезгә тазалык, муллык бирсен!

*(Янында торган ханымнарга карый.)*

Әйдәгез, балалар үз юлларын дәвам итсен, без бер дога кылып алыйк.

*(Утырып дога кылалар.)*

**Балалар** *(кычкырып чыгып китәләр)*:
*Ит, йомырка, ярма, май!*
*Өйдәме, түтәй?*
*Тизрәк бир күкәй.*
*Бирсәң безгә өч күкәй,*
*Тавыгың салыр йөз күкәй.*
*Май кирәк, ярма кирәк,*
*Карга туена бар да кирәк.*
*Шикәр кирәк, тоз кирәк, чыгар әби тизрәк.*
*Синең кебек уңган әби*
*Бу дөньяда бик сирәк.*

*(Балалар җыелган ярманы ботка пешерүчегә бирәләр.)*

**Ботка пешерүче әби:** Балалар, ярма да бар, май да бар, тоз-шикәр дә бар *(капчыктан чыгарып күрсәтә)*. Ботка пешерергә кызлар-малайлар елгадан су алып бирмәсләр микән? Елга суы белән ботка бик тәмле була торган иде.



**1 нче алып баручы:** Әнә безнең уңган, өлгер кызларыбыз боткага суны алып та менәләр.
**Ботка пешерүче әби:** Оланнар, бар нәрсә дә бар, мин ботка пешерим, ә сез бераз уйнап алыгыз.
**2 нче алып баручы:** Бәйрәмнәр, өмәләр, уен-җырсыз, шаярусыз үтмәгән. Бәйрәм тамашасының уеннары борынгыдан калган – халыкныкы. Менә алар: «Кырау куу», «Йомырка тәгәрәтү», «Капкалы», «Назалы» һәм башкалар... Без сезне уеннарга чакырабыз! Җиңүчеләрне дә, катнашучыларны да бүләкләр көтә.

*(«Челтәр элдем читәнгә» җырлы-биюле уен башкарыла.)*

## «КЫРАУ КУУ» УЕНЫ

Әлеге уен игеннәр чәчелеп беткәч үткәрелә торган йола белән бәйле. Халык иске чабаталар алып чыгып, басуның яртысына җиткәнче бер-берсенә чабата белән атышып, кырау куганнар. Кырау куып туктагач, чабаталарын бергә өеп яндырганнар.
*Кырау бездән кит-кит,*
*Кояш чык-чык,*
*Тәмле ботка бирермен,*
*Тәмле ботка казанда,*
*Тәти кашык базарда.*
*Тәти кашык саф алтын,*
*Кирәкми безгә салкын.*

## «ЙОМЫРКА ТӘГӘРӘТҮ» УЕНЫ

Йомырка – «Зәрә» бәйрәменең ин мөһим элементы санала. Ул Җиһанны гәүдәләндерүче символ буларак кабул ителә. Балалар таудан пешкән йомырканы тәгәрәтеп уйныйлар. Берәүләр тәгәрәтә, икенчеләре тау астында әлеге йомырканы тотарга тырыша. Йомырка тәгәрәтү җирне орлыкландыруны аңлата, мул уңыш алуга йөз тотып эшләнә. Шулай ук әлеге йоланы башкару балаларда кечкенәдән коллективлык хисен, дуслыкны ныгытуга булыша.

## «ТИРМӘ-ЙОРТ» УЕНЫ

Балалар дүрт төркемгә бүленеп, мәйданның дүрт почмагына баса. Һәр почмакта берәр урындык, урындык башына яулык куелган. Көй башлангач, балалар түгәрәкләнеп басып җырлыйлар, җыр тәмамлануга үз йортларына кайтып яулыкны баш очына күтәреп, тирмә-шатер ясыйлар. Иң беренче шатер ясаган төркем җиңүче була.

*(Бәйрәмдә «Аллария-ләрия», «Мәликә», «Чума үрдәк, чума каз», «Ал тирәк-күк тирәк», «Яулык салыш», «Йөзек салыш» уеннары уйнарга мөмкин.)*

**1 нче алып баручы:** Борынгыдан килгән йолалар һәрвакыт төрле ырымнар, серле тылсымлы такмаклар яки җырлар белән үрелеп бара һәм алар шул йолаларның аерылмас бер өлеше, аның бер бизәге булып тора. Аларда халыкның борынгыдан килгән ышанулары һәм күзаллавы чагыла. Ел фасылларына караган, кеше гомеренә, көнкүрешенә, балалар дөньясына багышланган бик күп йолалар, гореф-гадәтләр саклый халкыбыз.

**2 нче алып баручы:** Безнең бәйрәмгә еraклардан бик күп кунаклар кайткан. Әйдәгез, күмәк уен-җыр оештырабыз.

*(Кызлар, егетләр ике якка тезелеп, капма-каршы басалар. «Чүпләмле» уены уйныйлар.)*

**Бала:** Ботка пеште! Ботка пеште!

**1 нче алып баручы:** Кеше туганнан алып Җир-ана белән бик тыгыз бәйләнгән. Кендек каны тамган җир һәрвакыт үзенә тартып тора. «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра Туган ил дип», – юкка гына әйтмәгәннәр. Ерак җирләрдән сагынып кайткан кеше туган авылыннан үзенә көч-сихәт ала. Туган җир аңа көч-кодрәт бирә, үзенең йомшак җиле белән иркәли, челтерәп аккан саф сулы чишмә суы җанына сихәт бирә.

Җир-ана үзенең куенына салган һәр бөртеккә, орлыкка җылы сулышын өрә, шифалы яңгырлары белән шытып чыгарга ярдәм итә, иксез-чиксез иген кырларында дулкынланып үсәргә көч бирә һәм тук башаклары белән безне сөендерә. «И, Тәңрем, шушы орлыкларны җир куенына урнаштырып, мул уңыш алырга ярдәм итсәң иде», – дип мөрәҗәгать иткән борынгылар.

*(Бер өлкән апа уртага чыгып теләкләр тели, савыт белән ботканы Җир-анага бирә, бер-ике бала каргаларга бирергә дип чыгып китә.)*

**2 нче алып баручы:** Һәр халыкның рухи мәдәниятендә туган тел төп урынны алып тора. Халыкның туган теле, үз ана теле сакланган очракта гына аның милли йөзе, гореф-гадәтләре, йолалары саклана.

*Бөртекләп вә бөрәмтекләп җыйган,*
*Җәүһәрләрне барлар чак җиткән,*
*Гореф-гадәт, һөнәр югалмаган,*
*Күпме еллар, гасырлар үткән.*
*Каба белән җеп эрләгән әби,*
*Палас суккан безнең җиңгиләр.*
*Күреп баксаң, бездә искитмәле*
*Милли табын, милли киемнәр.*

**1 нче алып баручы:**

Күңелләрне рәхәтләндерә торган, җанга җылы бирә торган бәйрәмебез узып бара. Күгебез һәрчак сафлансын, өметләр аклансын, тормышларыбыз мул, имин булсын иде!

Бәйрәмнәр мөбәрәк булсын! Буыннарга дәрт, йөрәкләргә кодрәт илә куәт, җаннарыбызга иминлек, тынычлык иңдерсен! Ил-җиребез тыныч, бала-чагаларыбыз, кардәш-ыру, туган-тумачаларыбыз сау-сәламәт булсын!

Хөрмәтле дуслар, барчабызга да киләчәк бәйрәмнәрдә очрашырга насыйп булсын!

*(Бәйрәм уеннар һәм концерт номерлары белән үрелеп дәвам итә.)*

**Арча районында Сабантуй бәйрәме алдыннан «Бүләк җыю» йоласы уздырыла. Икенче төрле аны биредә «Мәйдан җыю» дип тә йөртәләр. Борынгыдан килгән әлеге матур бәйрәм чарасын һәр ел саен милли киемнәрдән, җырлап-биеп, күтәренке рух белән Арча мәдәният идарәсе хезмәткәрләре оештыра.**

# «Бүләк җыю» йоласы





Бүләк җыйганда матур бер гадәт тә сакланып калган, яшь киленнәр ул көнне аерым бүләк әзерли – үз куллары белән чиккән сөлге, кулъяулык, түбәтәй һәм калфакише бүләкләр тапшыра.

Бүләк җыючылар һәрбер хуҗалык янында туктыйлар, йорт хуҗаларын бәйрәм белән котлыйлар. Бүләкләр тапшыргач, «Сез бирсәгез биш күкәй, тавык салыр йөз күкәй» кебек такмаклар әйтеп җырлашалар. Егетләр тоткан колгага сөлгеләр бәйлиләр.

Иң мөһиме, ул көнне авылда гармун тавышы тынмый. Район, авыл халкы бүләк җыючыларга кушылып бии, җырлый.

**Ләйлә ХӘКИМОВА,**
**Арча, Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе**

Автор фоторәсемнәре

# *Сатыш авылының данлыклы мәдрәсәсе*




**Сатыш авылы мәдрәсә музее**

Казан губернасында иң борынгылардан саналган Сатыш мәдрәсәсе салынуга патшабикә Екатерина Iнең 1756 елның 23 августында мөселманнарга таш мәчетләр, мәдрәсәләр ачарга рөхсәт биргән Указы сәбәп була. Гыйлемгә омтылган халык, патша мәрхәмәтен тиз арада тормышка ашыра: губернаның иң ерак төбәкләрендә дә мәдрәсәләр ачыла. Аны ачканда авылның зурлыгы, халкының тормыш хәле, бигрәк тә байлар, белемле кешеләр булуы исәпкә алына. Шулай итеп, 1798 елда Сатыш авылында да мәдрәсә эшли башлый.

Мәдрәсәне башта дини белем бирүне күздә тотып ачсалар, соңрак биредә дөньяви фәннәр дә укытыла башлый. Уку татар телендә алып барыла. Сатыш халкы 1875 елга кадәр мәдрәсәдә рус телен укытуга каршы була.


Мәдрәсәне тәмамлаган күренекле шәхесләр арасында шагыйрь Миргазиз Укмаси, язучы һәм әдәбият белгече Мөхәммәт Гали, ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе булып эшләгән Рәүф Сабиров, Казанчы Бигәнәй авылында яшәгән, дәвалау белән шөгыльләнгән дин эшлеклесе Вәлиәхмәт ишан Мөхәммәтгалим угылы (Ишан хәзрәт, Бигәнәй хәзрәт), Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулла Мәһдиев, Шәүкәт Биктимеровның әтисе Хәсән Биктимеров та бар.

Сатыштагы икенче мәдрәсә бинасы 1893 елда борынгы нигезендә төзелә башлый. Аны, үзендә ялланып эшләүчеләрнең балаларына гыйбадәт кылу, укыту өчен дип, Кукмара районының Зур Сәрдек авылында яшәгән Хаҗи Насыйбуллин салдыра. Ул Саба якларына йон җыеп, эшкәртү максатыннан килә. Сатышта йон саклау складын да төзетә. Әлеге уку йорты революциягә (1918 елга) кадәр мәдрәсә буларак эшли. Аннан соң ябыла. Соңрак ясле, мәктәп булып тора. Яңа мәктәп салынгач, мәктәп музее, аннан склад була.

Авыл халкы мәдрәсә бинасын төзекләндерү турында хыяллана. Һәм хыяллары тормышка аша: республикадагы «Мирас» максатчан программасы буенча реставрацияләнергә тиешле тарихи объектлар арасында Сатыш авылы мәдрәсә бинасы да була. Республика Президенты Р.Н. Миңнеханов, Саба районы башлыгы Р.Н. Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы мәдәният министры А.М. Сибагатуллин ярдәме белән 2014 елда мәдрәсә бинасында төзекләндерү эшләре башлана. 2018 елда ул тәмамланып, мәдрәсә музей буларак эшли башлый.

Музейның төп юнәлеше – дин. Биредә иң кыйммәтле экспонатлар: дини китаплар, шәкерт сумкасы, бөти, мәдрәсә бинасы макеты, имам киеме, татар хатын-кызлары һәм ир-атлар киеме, түбәтәйләр, яулыклар, кулдан эшләнгән сөлгеләр һәм башкалар саклана. Шулай ук, музей заманча технологияләр белән дә җиһазландырылган: Саба районының интерактив картасында кыскача авыллар тарихы, мәчетләрнең фотосурәтләре һәм аның әчке күренеше турында мәгълүмат белән танышырга мөмкин. Шулай ук экскурсиягә килүчеләрдә изге Мәккә шәһәреннән турыдан-туры эфир да зур кызыксыну уята.

Музей фондлары даими рәвештә тулыландырыла. Бүгенге көндә биредә 138 экспонат саклана.






**Мәдрәсә музеенда саклана торган экспонатлар**

Мәдрәсә музей буларак эшли башлагач, республикабызның төрле районнарыннан, шулай ук чит төбәкләрдә яшәүчеләр дә кызыксынып киләләр. Мисал өчен, Омск өлкәсенең Тара районы Ишәй авылыннан Гөлшат Сатышева, үзенең тамырларын Сатыш авылы белән бәйледер дип, бер төркем авылдашлары белән безнең якларда кунак булып киттеләр. Пятигорскида яшәүче ханым да, авылга кайткач, музейга үзенең нәселен эзләп килгән иде. Сөнгатулла Мәһдиев, имам Габдрахман Мөхәммәтовның оныклары да бабалары укыган мәдрәсә тарихы белән кызыксынып, әлеге бинаның сакланып калуына соклануларын белдерделәр. Шулай ук Кытай, Куба республикаларыннан, Дагестаннан, Төркиядән, Кырымнан, Уфа шәһәреннән дә килүчеләр бар.

Мәдрәсә музеенда экскурсияләр белән бергә төрле мәдәни чаралар да оештырыла. Үткәрелгән чараларда авылыбыз өлкәннәре, шулай ук укучы балалар бик теләп катнаша. 2020 елда мәдрәсә музеенда «Туган якны өйрәнүчеләр» клубы оештырылып, бүгенге көнгә кадәр уңышлы гына эшләп килә. Утырышларда авыл, мәдрәсә тарихына багышланган мәгълүматлар барлана. Әлеге мәгълүматларны барлауда безгә авылдашларыбыз да зур ярдәм күрсәтә.

**Гөлгенә ШӘРИФУЛЛИНА,**
**Саба, Сатыш мәдрәсә музее хезмәткәре**

Г. Латыйпова фоторәсемнәре




# Йола фольклоры

**Татар халык иҗаты: 25 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021 – 2 т.: Йола фольклоры / (төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина). – 2022. – 541 б.**

Татар халкының йола фольклорын тулы бер комплекс (хәрәкәт һәм сүз берлеге) итеп күз алдына бастыру юнәлешендә төзелгән фәнни хезмәт – татар фольклористикасында беренче тәҗрибә. Әлеге өлкәгә караган материалларның жанр үзенчәлекләре ягыннан ырым, ышану, тыю (табу), йола җырлары, арбаулар, алкышлар, сыктаулар, келәүләр һәм башкалар кебек төркемнәргә һәм йолаларны тасвирлаган текстларга бүленүен истә тотып, язмаларны тематик классификация нигезендә урнаштыру үзен аклар дигән нәтиҗәгә киленде. Томга текстларны сайлап алганда, иң беренче чиратта аларның жанрга мөнәсәбәте түгел, ә бәлки билгеле бер йола комплексына каравы һәм шул турыда мәгълүмат бирү мөмкинлеге күз алдында тотылды. Шуңа күрә дә беренче карашка жанры ягыннан башка томнарга кертелергә тиеш кебек тоелган аерым язмалар (йола фольклоры белән бәйле ышанулар һәм текстлар һәм башкалар) нәкъ менә татар йола фольклорын бер система буларак тергезү максатыннан әлеге хезмәттә урын алды.

Билгеле булганча, халык мәдәнияте, шул исәптән фольклор да, гасырлар дәвамында үзгәреш кичерә: ниндидер күренешләр һәм жанрлар, гамәли һәм магик нигезләре югалу сәбәпле, кулланылыштан төшеп кала, алар урынын башкалары ала, заманга бәйле рәвештә туган яңа формалар гамәлгә керә. Йола фольклоры турында сүз алып барганда да әлеге үзгәрешләрне исәптә тоту зарур. Тупланган текстларны томга урнаштырганда, без татар халкы өчен традицион дип кабул ителгән йолаларны XIX гасыр ахыры – XX йөз башы хезмәтләрендә урын алган йола күренешләреннән башлап, XX йөз дәвамында экспедицияләр барышында язып алынган, галимнәрнең хезмәтләрендә, җыентыкларда урнаштырылган текстлар белән эзлекле рәвештә дәвам итүне кулай күрдек. Томда тасвирланган һәр йоланың төзелеше татар халкының традицион күзаллавы нигезендә тәкъдим ителде.

Әмма татар йола фольклорының үзенчәлекле күренешләрен күз алдына бастыру өчен, җирле традицияләрдә таралыш тапкан йола-гадәтләрнең һәм текстлар да хезмәттә өлешчә урын алды.

Йола белән бәйле фольклор текстлары, йола күренешләре, хәтта алар бертөрле аталып йөртелгән очракта да, төрле урында, төрле башкаручылар репертуарында төрле-төрле вариантларда, версияләрдә яши. Томга аларның иң әһәмиятлеләре, мәгълүмат бирү җәһәтеннән иң камилләре, билгеле бер йола комплексын татарларның һәр этнографик төркеменә хас булган гомуми структурада күзалларга ярдәм итә торганнары урнаштырылды. Кульязма фондларында саклаган бүтән вариант һәм версияләргә караган мәгълүмат «Искәрмәләр» бүлегендә күрсәтелде, һәр текстның кайчан, кайда, кемнән, кем тарафыннан язып алынуы, кайда саклануы

хакында белешмәне дә шул бүлектән табарга була.

Томның киң катлау укучылар өчен чыгарылуын исәпкә алып, иске татар телендә язылган әсәрләрнең теле җиңеләйтелеп, хәзерге орфография һәм грамматика нормаларына туры китереп алынды. Ләкин архаик, алынма һәм диалекталь сүзләр, нигездә, сакланып, аларга бит астында сүзлекчә биреп барылды. Географик яктан мәгълүмат татарларның төп этник төркемнәре яшәгән төбәкләргә карый, шул рәвешле татар халкының төрле этник төркемнәрендә кулланылган йола лексикасы диалекталь үзенчәлекләрен саклаган хәлдә фәнни әйләнешкә кертелә.

Текстлар «Календарь йола иҗаты» һәм «Гаилә-көнкүреш йола иҗаты» дигән төп ике зур төркемгә бүленде, һәр төркем үз эченә берничә тематик бүлекне берләштерә һәм төрле йола жанры үрнәкләрен үз эченә ала.

...Татар халкының йола фольклоры – гасырлар буена халыкның тормыш-көнкүрешен, күңел тынычлыгын, камил яшәешен тәэмин итеп килгән бай мирас. Адәм баласы йола белән туган, йола белән көн иткән, йола белән дөнья куйган. Баланың дөньяга килүенә бәйле гамәлләр, туйны җиренә җиткереп, нәсел-ыру каршында йөзгә кызыллык китермәслек итеп башкару, кешене соңгы юлга озату, хуҗалык эшләрен борынгыдан килгән тәҗрибәгә һәм табигатьтәге үзгәрешләргә яраклаштырып алып бару – болар барысы да махсус кануннар һәм йолалар ярдәмендә тәртипкә салынган булган. Туганнан алып соңгы көнгәчә кешенең яшәеше шулай билгеләнгән, шул канун һәм йолаларны, шуларга бәйле рәвештә туган авыз-тел иҗатын халык буыннан-буынга күчерә килгән. Йола фольклоры – ышануларны, шигъри сүзтезмәләрне, калыплашкан хәрәкәт-гамәлләрне һәм халыкның күпгасырлык акыл тәҗрибәсен туплаган рухи мирас. Шуңа да төрле фәнни өлкәләрдә эшләгән галимнәрнең әлеге бай мирасыбызны даими рәвештә өйрәнергә тиешлеге, ә милләтебезнең киләчәге булган яшь буынның аны билгеле бер дәрәҗәдә белергә тиешлеге бәхәссез.

**Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА,**
**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы**

# ЧӘЧҮГӘ ЧЫГУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЙОЛАЛАР

93. Чәчүгә чыгам бүген, ди, очраган кешегә йомырка бирә. Йомырка кебек каталансын[1] иген, ди, бер-ике йомырка алып чыга сукага чыккан көнендә. Юлында кем пирут[2] очрый, шуңарга бирә.

***

Капчыкларга салынган игенне төйиләр дә аның өстенә йомырка куялар. «Йомырка шикелле игеннең башы авыр гына булсын, тук булсын, ач булмасын, – дип. – Игенемнең сәдакасы булсын, – дип хәер дә бирә, – юлым уңсын, игенем уңсын», – дип бирә.

***

Кырга чыккан вакытта югары киштәгә үпмәк[3] күтәрәләр иде. «Яхшы, хәерле еллар булсын, – дип, – ашлыклы еллар булсын», – дип, хәергә атына[4] салынган питырас[5] бирә.

***

Питырас кечкенә үпмәк буладыр. Питырасын сәдакага бирә. Өч үпмәк сала, дүртенчесе питырас була. Аны сәдакага сала.

94. Чәчүгә чыккан көнне камыр баса идек, шуны иләккә сыдыра идек. Шуны пичкә куясың. Каймак белән ашыйлар бодай чәчкән көнне, жуача була. Иртәнге өчтән пешерәләр иде, ирләргә кушалларга[6] куялар ашларын. Чәчүгә барганда

[1] Каталансын – тәгәрәсен.
[2] Пирут – алдан.
[3] Үпмәк – икмәк.
[4] Атына – аерым, атаклап.
[5] Питырас – вак күмәч.
[6] Кушал – корзинка.



пешерәләр иде, төн зәрәдән[7] торып. «Игеннәрнең башаклары тук булсын, эре булсын», – дип.

95. Чәчүгә чыкканда «шыйлык боткасы» пешерәләр. Тубалдан ашлык белән бергә күкәй сибеп баралар. Аларны балалар җыя торган иде. Әйтеп ашауны карчыклар белде аны. Без, балалар, алар артыннан кабатлап торабыз:

Уңышлар әйбәт булсын,
Дөньялар, җирләр, күкләр тыныч булсын,
Шушы уңышларны дуслар,
Туганнар белән ашарга язсын.

Дошманга да яхшылыклар телибез андый җирләрдә:

Дошманнар да тук булсын, ач булмасын.
Шушы ашлыкларны чәчәбез,
Аны урып алырга
Аллаһ Тәгалә көч бирсен, дәрт бирсен!
Башаклары тук булсын,
Төпләре нык булсын,
Авыл-күршеләр исән-сау булып,
Бергәләп ашасак иде,
Безгә ризыкка язсын иде,
Дөньялар тыныч булсын иде!

[7] Төн зәрәдән – иртән иртүк, таң атканда.

96. Чәчүгә чыкканда, бер урынга, тау башына менәләр дә балалар белән бергәләп күкәй тәгәрәтәләр. Әниләр тегеп бирерләр иде тастымалдан бер кечкенә капчык. Шул капчык белән күкәй җыярга чыга торган идек. Ничә күкәй була, барысын да шул капчыкка салып, күкәй тәгәрәтә торган җиргә йөгерә идек. «Менә шул җирдә күкәй тәгәрәрлек булгач кына чәчүгә чыгарга ярый», – дигәннәр. Ырымы шул булган. Шунда күкәй тәгәрәмәсә, чәчүгә чыкмыйлар. Менә шундый җир ул. «Мулла абзыйлар җире» дип әйткәннәр аны.

97. Чәчүгә чыкканда, билләреннән чи күкәйне уратып, бил тирәли әйләндереп, теләк теләп, әбиләр хәер бирәләр. Күкәйләрне күршегә, балалы кешеләргә кертәләр.

Он салабыз да, он өстенә биш-алты күкәй салып, хәергә кертәбез:

Игеннәр уңсын!
Исән-сау җыйнап алырга язсын!
Балалар белән ашарга язсын!

98. Орлык чыккан көн. Әйбәтләп, һәрбер хуҗалык үзенең семьясы белән, пешкән кызыл күкәйләрне алып, үзенең чәчелә торган ризыгы белән басуга барып, әйбәтләп бөтенесе бергә утырып, шул чәчәргә тиешле булган ашлыкны чәчеп кайта торган булганнар. Шунда басуда

бәйрәм ясап кайтканнар. Аерым хуҗалык вакытында монысы. Ул – беренче чәчү, орлык чыгара торган көн, шул көнне күкәй чәчәләр.

99. Чәчүгә чыккач, йомырка ыргыту бар: «Мул булсын, уңыш булсын!» – дип ыргыталар. Хәзер юк инде ул, юк. Җиргә ватмыйча ыргытып җибәрәләр иде.

100. Орлык чыккан көнне җир башында күкәй тәгәрәткәннәр. Без бара торган идек басуга, күкәй эләктерергә. Бабай, муенына тубалны киеп, тубалга бодай салып, бодаеның өстенә күкәйләрен куеп, бодайны учлап сибеп йөри. Менә шунда күкәйләрне дә берәм-берәм ыргыта. Без, балалар, йөгерешәбез инде күкәйләрне эләктерергә. Зурраклар ала инде, бәләкәйләргә бик эләкми бит. Бабай күрә дә теге күкәйсез калган баланың алдына ташлап куя күкәйне.

101. Капчыкларга игеннәр төйиләр, арпасын, бодаен... Аның өстенә йомыркалар куялар.
Игенемнең сәдакасы булсын,
Игенем уңсын,
Юлым уңсын, – дип хәер бирәләр бер олы кешегә.

102. Җир хуҗасы – Суар ата,
Суар ата су ярата.
Иген тулы нугратта[8],
Бир, Ходаем, мул уңыш.
Игенем түгел капта,
Игенем киң өсәктә[9].
Иген биру – синнән,
Хезмәт – миннән.
Әремнәр, шаһит булыгыз,
Бер Ходаем, тапшырдым.

103. «Бүген орлык чыгарабыз», – дип, кеше саен күкәй җыялар иде. Ул көнне басуга беренче кат чыгалар бит, орлык белән чыгалар. Күкәйләрне тубалга салып чыгарганнар. Тубал юкәдән була. Орлык тубалына күкәйләр салганнар. «Орлыклар күкәй күк тук булсыннар», – дип, басу буйга күкәйләр тәгәрәткәннәр.

Кояшка таба карап, кыйблага карап, Ходайдан сораганнар:
Икмәкләр булсын,
Ил бай булсын,
Бар кеше дә тук булсын,
Сугышлар булмасын,
Тынычлык булсын,
Дөньялар имин булсын.

104. Орлык чыгару көнендә теләк телибез. Җир анасына, Җир атасына башырып[10] телибез:
Бөртек янына бөртек бир,
Учма янына учма бир,
Учма янына көлтә бир,
Көлтә янына чүмәлә бир,
Чүмәлә янына кибән бир,
Кибәннәрне сугып, ипи ашарга язсын!

105. Җир атасы – Җирән сакал!
Җир анасы – Асылбикә!
Түбәсенә туклыгын бир,
Тамырына ныклыгын бир,
Ил өстенә муллыгын бир,
Ил эчендә безгә дә бир!
Башлыйк теләкне,
Күтәрик беләкне, –
Кояш, шаһит бул!

[8] Нуграт – амбар.
[9] Өсәк – лар.
[10] Башырып (баш орып) – башны түбән иеп

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар*:**

93. I. Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче мишәр татарларыннан Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2001, 185 б.
94. I. Рязань өлкәсендә Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 260 б.
95. I. Татарстанның Мамадыш районы Җөри авылында Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2020, 303–304 б.
96. I. Татарстанның Әтнә районы Төрекләр авылында Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 265 б.
97. I. Оренбург өлкәсе Сакмар районы Үрге Чебенле авылында Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 269 б.
98. I. Мирасханә. Татарстанның Мамадыш районы Дүсмәт авылында М.С. Жилкинадан (1923 елгы) И.Г. Закирова язып алган.
99. I. Татарстанның Арча районында И.И. Ямалтдинов язып алган. Милли мәдәни мирасыбыз: Арча, 132 б.
100. I. Ногайбәк керәшеннәреннән Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 253 б.
101. I. Саратов өлкәсенең Алтата авылында Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 253 б.
102. I. Спасс өязенең Әлки авылында Г.М. Хисаметдинов язып алган. Уразманова, 60 б. Әлеге сүзләр чәчүгә беренче көн чыкканда, җиргә сәдака итеп йомырка күмгәндә әйтелгән.
103. I. Татарстанның Минзәлә районында Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 252 б.
104. I. Түбән Кама керәшеннәреннән Ф.С. Баязитова язып алган. Баязитова, 2019, 252 б.
105. I. ТХИ: Йола һәм уен җырлары, 50 б. II. Мөхәммәтҗанов, 1977, 160 б.

*(I. Әсәрнең китапка кайдан алынуын күрсәткән төп чыганак.)
(II. Текст басылган башка чыганаклар.)

# ЧЫНГА АШКАН БАЛАЧАК ХЫЯЛЫ

*Алсу ӘСКӘРОВА,*
*Әтнә үзәк китапханәсе җитәкчесе,*
*Олы Әтнә авылы*

**Язмамның герое – балачак хыялын тормышка ашыра алган ханым, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Алия Абдуллина. Ул үз-үзен белгәннән бирле бии. Балалар бакчасындагы тәрбияче апасы да тиктормас, терекөмештәй хәрәкәтчән, курчактай матур кызга яратып «Ал чәчәк» дип эндәшә.**

Үсә төшкәч ул, дус кызларын җыеп, үзлегеннән биюләр куя – мәктәптәге кечә-бәйрәмнәр дә аның чыгышыннан башка узмый. Мәктәпне тәмамлауга Алабуга мәдәният училищесының хореография бүлегенә укырга киткән Алия, беренче курстан соң Олы Әтнә мәдәният йортына практикага кайтып, район Сабантуеның ачылышына күмәк бию әзерли.

2003 елда укуын тәмамлагач та, туган җиреннән ерак китәргә ашыкмый яшь кыз. Авылга әти-әнисе, туганнары янына кайтып, район мәдәният йортына балетмейстер булып эшкә урнаша һәм биючеләр төркеме туплауга керешә. Үзе оештырган балалар бию коллективына балачактагы ягымлы кушаматын – «Ал чәчәк» исемен тәкъдим итә. Бер елдан район сәхнәсендә «Ал чәчәк» бию коллективының хисап концертын оештыра. Шушы тәүге уңыштан соң Алия үз алдына максат куя – Әтнә балалары дөньяга танылырга, район, Татарстан сәхнәләре белән генә чикләнеп калмыйча, Россия күләмендәге бәйгеләрдә дә катнашырга, җиңүләр яуларга тиеш!

2006 елда районда Әтнә балалар сәнгать мәктәбе ачыла һәм аның җитәкчесе итеп Алия Ринат кызы билгеләнә. «Ал чәчәк» төркеме дә бер баскычка күтәрелә – хәзер биюче кызлар авыл үзешчәннәре генә түгел, ә башлангыч сәнгать белеме алучы укучылар. Коллективның уңышларын район халкы да тиз таный, әти-әниләр нәни кызчыкларын хореография бүлегенә укырга китерә башлый. Бию коллективы җитәкчесе, үз эшенең остасы Алия балалар

> **«Ал чәчәк» бию коллективы бүгенге көндә республикабызның иң көчле бию төркемнәре рәтендә. Ул Әтнәдә, Татарстанда гына түгел, Россиядә, хәтта чит төбәкләрдә дә танылырга өлгерде.**



Алия Абдуллина



белән уртак тел табып, алар белән бер дулкында яши. Укучыларда бию сәнгатенә мәхәббәт кенә тәрбияләп калмый, һәр баланың яхшы физик әзерлекле булып үсүенә һәм дисциплинага да зур игътибар бирә. Ул алар өчен остаз да, киңәшче дә, дус та була белә. Алия һәр балага индивидуаль якын килеп, иңнәренә зур җаваплылык алып, бию төркемен төрле дәрәҗәдәге фестивальләргә, бәйгеләргә әзерли, зур сәхнәләргә алып чыга, югары исемнәр ала, җиңү арты җиңү яулый.


«Ал чәчәк» бию коллективы бүгенге көндә республикабызның иң көчле бию төркемнәре рәтендә. Ул Әтнәдә, Татарстанда гына түгел, Россиядә, хәтта чит төбәкләрдә дә танылырга өлгерде.









**«Созвездие-Йолдызлык» телевизион балалар эстрада сәнгате фестиваленең «хореография» номинациясендә күпсанлы җиңүче, «Созвездие-Йолдызлык»ның гран-при иясе, Бөтенроссия һәм халыкара бию бәйгеләре лауреаты һәм гран-при иясе. Түбән Новгород шәһәрендә үткәрелгән халыкара фестивальнең гала концертында Россиянең танылган «Тодес» бию коллективы белән бер сәхнәдә чыгыш ясавы да «Ал чәчәк» бию коллективының дәрәҗәсе югары булуын раслый. 2022 елда коллектив Татарстан Президентының махсус сертификатына һәм 2023 елда Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле тарафыннан «Достояние Республики» махсус призына лаек булды.**

**Сәхнәгә куелган һәр биюнең үз тарихы, үз башкару стиле бар. Һәр чыгыш үзенчәлекле, кабатланмас, көчле, һәм, иң мөһиме, милли!**

«Ал чәчәк» үрнәк бию коллективы балалар өчен – тормыш мәктәбе ул. Күпсанлы фестиваль-бәйгеләр, дәрәҗәле кичәләрдә чыгыш ясаулар коллективны рухи яктан бик нык баета. Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан шәһәренең күп кенә танылган хореографлары Әтнәгә килеп, мастер-класслар бирүләре, укучыларны техник яктан үстерүләре, осталык дәрәҗәсен күтәрүләре дә «Ал чәчәк» коллективының профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнүен күрсәтә. Гади авыл баласына профессиональ белгечләр белән очрашу, аралашу, алардан дәрес алу мөмкинлеге зур йогынты ясый, ныклы этәргеч бирә.

Коллективның тормышында аерым бер мохит хөкем сөрә – балалар бию белән яши, иҗат белән яна, аларның һәрберсе сәләтле, чыгышларыннан эмоция, яшьлек дәрте ташып тора, дулкынлану катыш шатлык хисе бөркелә, алар киләчәктә дә үз-үзенә ышанган, үрнәк шәхесләр булып формалаша. «Ал чәчәк» коллективы оешканнан башлап күпме бала бию коллективына килеп, үз бәхетен сынап карагандыр. Балаларыбыз илебезнең кайсы гына төбәгендә, кайсы гына сәхнәсендә чыгыш ясаса да, үзләрен югары дәрәҗәдә күрсәтәләр, чөнки алар сәләтле һәм тырыш, затлы һәм зәвыклы, тәртипле һәм тәрбияле.

Коллективның репертуары җитәкченең иҗади фантазиясе нигезендә формалаша һәм даими рәвештә яңа оригиналь хореографик композицияләр белән яңартыла. Ә аның репертуары бай, Алия Ринат кызы биюнең төрле жанрларын, төрләрен һәм формаларын куллана – халык, фольклор, стильләштерелгән халык биюләренә зур өстенлек бирә, заманча биюләрне, эстрада биюләрен дә үз итә, яңа хореографик юнәлешләрне дә үзләштерә. Коллектив репертуарында Россия һәм дөнья халыкларының 15 биюе бар. Сәхнәгә куелган биюләр тамашачылар тарафыннан гына түгел, ә республиканың һәм Россиянең танылган хореографлары тарафыннан да зур соклану белән кабул ителә. Аларның чыгышларында милли ассызык ярылып ята, татар рухы бөркелеп тора. Сәхнәгә куелган һәр биюнең үз тарихы, үз башкару стиле бар. Аларның һәрберсе йокысыз төннәр, тынгысыз көннәр, уйланулар, фикер алышулар, идея туплау, күпсанлы репетицияләр, тырыш хезмәт аша туган. Һәр чыгыш үзенчәлекле, кабатланмас, көчле, һәм, иң мөһиме, милли!

«Ал чәчәк»нең бүгенгесе – Алия Абдуллинаның яратып, яшәү мәгънәсен биюдә күреп башкарган 20 еллык хезмәте нәтиҗәсе. «Хезмәтеңне тиешле дәрәҗәдә, йөрәгең аша уздырып, бар күңелеңне биреп башкарасың икән – уңыш сиңа үзе киләчәк», – дип саный тынгысыз һәм хыялый җитәкче. Бүген аның күңелендә үзе тудырган, баласыдай кадерләп, тәрбияләп үстергән «Ал чәчәге» белән горурланудан бигрәк шатлык һәм рәхмәт хисе, чөнки бу югары үрләр, күркәм җиңүләр, матур уңышлар коллективның, хезмәттәшләренең күмәк хезмәте билгесе. Үз укучыларында бию сәнгатенә мәхәббәт тәрбияли алуы белән, аның юлыннан баручы дәвамчылары булуы белән ул икеләтә бәхетле.

Озак еллар үзенең тырыш хезмәтенә, иҗатына илһамны балачак хыялы булган, яратып башкарган эшеннән, күзенә генә карап торган биюче балаларыннан, һәр башлангычына терәк булган гаиләсеннән, әти-әнисеннән, ярдәм кулы сузучы җитәкчеләрдән ала. «Билгеле инде, өйдә бер-береңә ышаныч булмаса, якыннарымның терәген, ярдәмен тоймасам, сәнгать өлкәсендә болай озак еллар эшли алмас идем», – ди ул.

«Кеше гомеренең биек нокталары була. Әнә шул биеклектән караганда, узган юлың уч төбендәге сызыклар төсле күренеп ята», – дип язган күренекле әдибебез Гариф Ахунов. Алия ханымның да бүген әнә шул биеклектән карарга хакы бар. Аның үзенә, гаиләсенә, коллективына, иҗатташларына алга таба да куанычлы мизгелләр, зур уңышлар, югары үрләр, дәрәҗәле исемнәр насыйп булсын.

**Кукмара районының Почкучук урта мәктәбендә Җиңү көне зурлап уздырыла. Мәктәп коллективы, укучылар «Үлемсез полк» чарасында катнашалар, авыл халкы белән бергәләп урамнарны әйләнәләр.**









**Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тантаналы митингта Осиново бистәсенең С.К. Гыйматдинов исемендәге гимназия укучылары һәм укытучылары да катнашты.**

# ҖИҢҮ КӨНЕНДӘ

**Наилә Яхина көе**
**Рифә Рахман шигыре**




*Җиңү көне! Бүген самолетлар,*
*Очып уза йортлар өстеннән.*
*Бәйрәм салютлары аккордыннан*
*Күңел тула көчле хис белән.*

***Кушымта:***
*Җиңү авазлары ишетелә,*
*Кош җырында, җилләр телендә, –*
*Сагыш катыш шатлык булып, бәйрәм*
*Килеп керде минем өемә.*

*Җиңү парадында яше-карты,*
*Көй уйнатып асфальт юллардан.*
*Атлап бердәй йөрәк тибешенә,*
*Колонналар уза урамнан.*

***Кушымта.***

*Дәртле җырлар, бәйрәм котлаулары*
*Дәшеп алган Казан түренә.*
*Иңне иңгә куеп, Җиңү көне*
*Парад булып атлый илемдә.*

***Кушымта:***
*Җиңү авазлары ишетелә,*
*Кош җырында, җилләр телендә, –*
*Сагыш катыш шатлык булып, бәйрәм*
*Килеп керде минем өемә.*
*Сагыш катыш шатлык булып, бәйрәм*
*Аяк баскан Туган җиремә.*

# Борай бәлеше

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Рубриканы «Тәмле булсын» рестораннар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара.

**Бәлеш – камыр эченә төрле эчлекләр салып мичтә пешерелгән кунак ашы. Татар халкында бәлешнең нинди генә төре юк: дөгеле бәлеш, борай бәлеше, ит бәлеше...**



Бәйрәмнәрдә авылга кайтсаң, һәр йорттан бәлеш исе килә. Әзли китсәң, һәр төбәкнең үз бәлеше... Кайбыч якларында карабодайныкын пешерсәләр, борай бәлеше – Кукмара ягы бренды. Файдасына килгәндә, башка бөртекле культуралардан аермалы буларак, борай ярмасында аксым күләме 27-35 процентка артыграк һәм бу ярмада кеше организмы өчен иң кирәк булган 18 аминокислота тупланган. Тимер, протеин һәм башка төрле витаминнар да гади бодай ярмасына караганда күбрәк. Составында җилемсәнең чагыштырмача түбән булуы аркасында аллергиядән интегүчеләр һәм ябыгырга теләүчеләр өчен ул диетик ризыклардан санала. Шулай ук йөрәк-кан тамырлары әйләнешен һәм ашкайнату системасын яхшырта. Клетчаткага бай булуы шикәр һәм холестерин күләмен көйләп торырга ярдәм итә. Һиндстанда һәм Италиядә борайны «кыяклы культураларның кара уылдыгы» дип йөртәләр.





## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**

600 грамм он,
1 данә йомырка,
ярты стаканнан (150 мл) күбрәк сөт,
150 грамм көнбагыш мае,
1 балкашыгы шикәр комы,
тәменчә тоз.

**Эчлек өчен:**

1,2 килограмм сыер ите,
1,5 килограмм борай,
4 данә суган,
200 грамм атланмай,
тәменчә тоз, борыч,
150-200 грамм шулпа.



**1** Эчлекне әзерләгәнче борайны бүртерергә кирәк. Ул чагыштырмача озак бүртә. Бүртерү өчен без аны 12 сәгатькә суга салып куябыз. Әгәр инде суга салынмаган булса, 1:15 исәбеннән суын саркытмыйча гына пешерәбез. Эчендә катысы беткәнче сүрән утта кайнатабыз. Аннан соң салкын суда әйбәтләп чайкап, суын саркыту өчен читкә алып куябыз.



**2** Савытка 150 грамм көнбагыш мае, 150 миллилитр сөт, тәменчә тоз, шикәр комы салып һәм 1 йомырка сытып, яхшылап болгатабыз. Өстенә онны өсти-өсти, савыт кырыена ябышмаслык булганчы, йомшак кына камыр басабыз. Аннары куна тактасына төшереп, камырны ял иттерәбез.



**3** Камыр ял иткән арада эчлек әзерлибез: ваклап туралган суганны майда алтынсу төскә кергәнче кыздырып алабыз. Итне шакмаклап турыйбыз. Әзер ярмага суганлы, итле-майлы катнашманы салып, әйбәтләп болгатабыз.



**4** Камырның дүрттән бер өлешен алып куеп, калган зуррак өлешен 4-5 миллиметр калынлыкта таба кырыеннан бераз чыгып торырлык итеп җәябез. Хәтта табаны камыр өстенә куеп үлчәп карарга мөмкин. Камыр ертылмасын өчен таба кырыен түгәрәкләп сөлге белән әйләндереп алабыз.



**5** Җәемне табага җәеп, уртасына әзер эчлекне салгач, өстенә эретеп атланмай сибәбез. Камырның кырыйларын күтәртеп бөгәбез. Аннары кечерәк камырны җәеп, бәлешнең өстенә ябабыз, читләрен чеметеп ябыштырабыз. Капкачын уртадан тишеп, калган камырдан бөке ясап каплап куябыз һәм төрле бизәкләр кисеп, бәлешне бизибез.



**6** Әзер бәлешне 180 С ка кадәр җылытылган духовкага тыгабыз. Өсте кызарып киткәннән соң, духовканың җылылыгын (160-170 С) киметәбез. Бәлешне 1-1,5 сәгать тотканнан соң, алып, бөкесен ачабыз һәм алдан әзерләп куелган шулпаны салабыз да, бөкесен ябып, тагын 5-10 минут тотабыз. Бәлеш әзер булгач, духовкадан алабыз, йомшарсын дип, бераз өстенә тастымал ябып торабыз.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Шахворд

Шахмат фигурасы атның дөрес йөреш тәртибе белән шагыйрь Ленар Шәеховның «Яз килә!» шигырен укыгыз.

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | е | т | к | ы | ә | р | л | ы | Е | я | С | ө | г | ы | е | н |
| ү | з | Җ | л | а | и | л | н, | ы | ә! | к | л | в | ы | н | а | б |
| б | е | б | з | б | ә | ә | | л | Я | и | | б | к | җ | ә | р |
| я | а | е | б | н | л | и | н | ф | | е | з | с | и | е | е | д |
| б | ы | р | ә | л | е | | | ә | ә | | к | г | и | и | ч | р |
| к | ә, | ә | к, | е | г | л | л | | р | р | н | | л | л | а | л |
| в | п | к | и | к | ә! | т | р | з | з | з | ә | н | л | л | җ | ы |
| л | р | а | ч | а | а | Я | й | ө | ы | е | ы | Я | ә, | ә | ә | б |
| е | а | җ | ч | з | ө | л | л | у | к | | е | к | е | ә, | к | и |
| ы | и | ә | ш | ы | п,- | к | п, | и | | г | и | | н, | я | о | н, |
| т | р | е | м | г | Я | р | к | | н | | ү | п, | я | б | т | л |
| к | К | м | ч | е | ш | е | и | я | а | е | ә, | л | з | Я | Б | з |
| э | к | ә | н | | е | з | р | л | л | ә, | К | м | е | з | а | ү |
| н, | з | л | о | ф | и | Г | ә! | З | л | л | и | ә | ш | к | к | ә |
| ы | р | а, | р | ө | Й | и | ч | ә! | л | н, | е | и | к | л | б | р |
| Я | ә | л | т | ә | е | а | ш | е | ы | н, | т | ү | а | л | х | и |
| а | л | н, | л | р | а | л | б | К | - | б | в | ә | е | т | ш | е |

**Шахвордның җавабы:**

Җылы көннәр җиту белән,
Карлар эреп бету белән,
Елгада боз киту белән,
Яз килә, яз килә!
Сыерчыклар шавы белән,
Кыр казлары явы белән,
Бәхет-шатлык тавы белән

Яз килә, яз килә!
Йомшак, нәфис җиле белән,
Зифа, нечкә биле белән,
Яшел чирәм җире белән
Яз килә, яз килә!
Гөлчәчәкләргә күмелеп,
Яз килә, нурга төренеп,
Каршы алыгыз йөгереп, –
Яз килә, яз килә!

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле даталар
2023

## ИЮЛЬ

**2 июль**

Җырчы, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Эмиль Госман улы Җәләлетдиновка 90 яшь (1933)

**4 июль**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия сәнгать академиясенең заманча сәнгать өлкәсендә Н.И. Фешин исемендәге премиясе лауреаты Газиз Гыйльметдин улы Гобәйдуллинга 75 яшь (1948)

**14 июль**

Шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марс Садри улы Шабаевның тууына 90 ел (1933-2008)

**21 июль**

Рәссам, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Николай Матвеевич Горлановка 70 яшь (1953)

**23 июль**

Композитор, дирижёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгуть Гали улы Латыйповның тууына 110 ел (1913-1987)

**27 июль**

Опера җырчысы, педагог, Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты Клара Әкрам кызы Хәйретдиновага 75 яшь (1948)

**29 июль**

Шагыйрә Фәридә Атилла кызы Рәсүлеваның тууына 75 ел (1948-2022)

**30 июль**

Каллиграф, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәҗип Фәйзрахман улы Нәккашка (Исмәгыйлевкә) 75 яшь (1948)

## АВГУСТ

**1 август**

Җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре докторы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура әгъзасы Ринат Зиннур улы Закировка 75 яшь (1948)

**1 август**

Татарстан Республикасының халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.-Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почётлы диплом иясе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Мөгаллим улы Миңнуллинның тууына 75 ел (1948-2020)

**4 август**

Шагыйрь, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстанның М. Җәлил исемендәге Республика, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Равил Габдрахман улы Фәйзуллинга 80 яшь (1943)

**14 август**

Композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Луиза Миңнегали кызы Батыр-Болгари (Батыркаевага) 70 яшь (1953)

**15 август**

Җырчы, педагог, ТАССРның халык артисты Асия Сафиулла кызы Измайлованың тууына 120 ел (1903-1993)

**23 август**

Язучы, тәрҗемәче, ТАССРның, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге премиясе лауреаты Ләбибә Фәез кызы Ихсанованың тууына 100 ел (1923-2010)

## СЕНТЯБРЬ

**1 сентябрь**

Эстрада җырчысы, РСФСРның атказанган, Татарстан Республикасының халык артисты Альберт Нурулла улы Әсәдуллинга 75 яшь (1948)

**6 сентябрь**

Композитор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әгъзам (Азантин) Нуретдин улы Фәттах (Фәттахетдиновның) тууына 100 ел (1923-2013)

**18 сентябрь**

Актёр, режиссёр, Татарстанның халык артисты Владимир Юрьевич Пряхинга 60 яшь (1963)

**19 сентябрь**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Луиза Әхмәтҗан кызы Хәйретдиновага 75 яшь (1948)

**23 сентябрь**

Җырчы, режиссёр, профессор, ТАССРның, РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нияз Курамша улы Даутовның тууына 110 ел (1913-1986)

**23 сентябрь**

Балет артисты, балетмейстер, РСФСРның атказанган артисты Әдһәм Фазылҗан улы Нарыковның тууына 100 ел (1923-1968)

**29 сентябрь**

Рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сергей Осипович Лывинның тууына 100 ел (1923-2000)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**





**Кадерле укучыларыбыз!**
2023 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!